КЫТАЙГА ЮЛ

Казанда узган «РОСТКИ» халыкара форумында татарлар белән кытайларның уртак тел табуының серен чиштеләр

> 2

МЫСКЫЛЛЫ САБАК

Мәктәп укучыларының яшьтәшләре тарафыннан эзәрлекләнүен ничек булдырмаска?

> 3

ТАРХАН СУЛЫШЫ

Сүнгәннән соң кабат ямьләнеп маташкан авылга сәяхәт

> 5

ИЛФАР КӘРИМОВ:

«Замана белән бергә радиотыңлаучылар да үзгәрде»

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 131–132 (29098–29099) | Сишәмбе | 12 сентябрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

РИЗЫГЫ ДА, БӘЯСЕ ДӘ ТӘМЛЕ

РЕСПУБЛИКАДА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ЯРМИНКӘЛӘРЕ БАШЛАНДЫ

Көзге уңыш

Бу шимбә шәһәрләрдә көзге ярминкәләр башланды. Авыл уңганнары иртә таңнан сәүдә нокталарында сату итте. Елдагыча, быел да алар бәяләр, мул ризык һәм җыр-бию белән кинәндерә.

«Казан» агросәнәгать паркына Мамадыш, Арча, Кукмара уңганнары килде. Арчалылар халыкны кайнар коймак һәм тәмле чәй белән сыйлады. Алар сату иткән урында халык аеруча күп иде.

– Төнге бердә йокыдан тордык. Иртәнге дүртенче яртыда без инде монда идек. Бишенче яртыда сатып алучылар килә башлады. Күбрәк олы яшьтәгеләр иде, – ди Югары Оры авылыннан килгән Рәмзия Сафиуллина. – Без башта сөт саттык. Иртәнге сигезенче яртыга 300 литр сөтебез бетте дә. Халык чират торып алды. Аннары сатып алучыларны коймак белән сыйладык. Самавыр кайнатып чәй ясадык. Октябрьдә тагын киләбез әле.

Ниләр генә юк монда! Арчалылар мунчалага кадәр сата. Мамадыш урман хуҗалыгы хезмәткәрләре агач үсентеләре алып килгән. Аларны да күз ачып йомганчы алып бетерделәр. Башкала халкы Кукмараның сөт ризыкларын да сыпыртып алды.

Кукмара районының Нырты авылында яшәүче Илшат Хамизов иртәнге тугызга алып килгән итен сатып та бетергән иде.

– Бәя узган елгы кебек калды. Килосы 460 сумнан башлана. Яңа гына суйган мал булгач, халык чират торып ала. Ярминкәләр безнең өчен бик әйбәт урын инде ул. Монда акча эшләп була. Казан халкы авыл ризыгының тәмен белде. Бик теләп алалар, – ди Илшат.

Ярминкәләрнең тагын бер үзенчәлеге бар – биредә рәхәтләнеп үзешчәннәр чыгышын тыңлап була. Ә алар башкала артистларыннан бер дә ким түгел. Матур итеп баянга кушылып җырлыйлар. Арча районының Сарай Чокырча авылыннан килгән Марсель абый иртәдән бирле баян уйнап, җырлап торган.

– Кукмара, Саба, Арча, Биектау районнарында туып-үскән кешеләр белән аралаштым. Мин уйнадым, алар җырлады. Кешеләр монда ризык кына алып китми, рухи байлык та туплый, – ди ул.

Дөрес әйтә. Инде сумкалары тулган килеш тә кайтырга ашыкмаучы кешеләр шактый иде.

– Мин бу ярминкәне көтеп алам. Монда Кукмара сөтен алырга дип киләм. Аларның эремчеге дә тәмле, каймагы да, мае да. Алар килмәгәндә башка җирдән алдым. Әмма анда кыйммәт. Ярминкәнең бәясе дә «тешләми» бит аның, – ди Мирхәйдәр Фәйзи урамында яшәүче Гөлфизә Саттарова.

Искәндәр Фәтхуллин икенче тапкыр килгән иде инде. Иртән улы белән килеп ике капчык бәрәңге, бер капчык суган, бер капчык кәбестә алып кайтканнар.

– Хатыным кәбестәне тозлап куя. Килосын 16 сумнан алдык. Хәтерләсәгез, берзаман кибеттә 60 сумнан да саттылар бит. Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренә чиксез рәхмәт. Алар безне ашата, – ди Искәндәр абый. – Бәяләрнең күтәрелмәгәненә сөендек. Аннары авылдан килгән ризык экологик яктан чистадыр дип тә ышанабыз. Мин күбрәк авыл җирлегеннән килүче шәхси бакчада үстерүчеләрдән алдым. Икенче атнага да чыгармын дип торам.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Илдар Мөхәммәтҗанов

БӘЯЛӘР (сумнарда)

	Ярминкәдә	Кибеттә
Бәрәңге (кг)	18	45–50
Кәбестә (кг)	16	30
Агызып ала торган сөт (литры)	40	
пакеттагы сөт (2,5 майлылык, 800 грамм)		45
Кишер (кг)	25	30
Чөгендер (кг)	16	24
Суган (кг)	22	28
Сыер ите (кг)	460–480	300 граммы – 270
Атланмай (кг)	540тан	180 граммы 110–139
Сыр (кг)	500дән	600–890
Он (кг)	30	40
Йомырка (дистәсе)	80–100	100–120
Шикәр комы (кг)	65	65–66

Сан

Көзге ярминкә һәр атнаның шимбәсендә 23 декабрьгә кадәр узачак. Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы матбугат үзәге мәгълүматларына караганда, ярминкәләр Казанда – 14, Чаллыда һәм Яшел Үзәндә – 2, Түбән Камада 3 мәйданда үткәрелә. Республиканың 26 районында да оештырыла сәүдә.

Быелгы беренче ярминкәдә 16 районның авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре 78,2 миллион сумлык товар саткан. Шәһәр халкына 546,1 тонна яшелчә (шуның 385,3 тоннасы бәрәңге), 17,3 тонна сөт, 75,9 тонна ит (шуның 47 тоннасы сыерныкы) алып килгәннәр.

Күп калмады

М12 түләүле юлының Арзамастан Казанга кадәрге өлеше 80 проценттан күбрәккә әзер. Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин әйтүенчә, төп эшләрнең берсе – Идел аша күпер ярларга тоташтырылган инде. Хәзерге вакытта биредә асфальт җәю, яктырткычлар, киртә-коймалар урнаштыру эшләре алып барыла. Декабрь ахырында Казанга кадәр юлны ачу күздә тотыла.

Идел елгасы аша күпергә асфальт-бетон түшәү эшләрен октябрьдә төгәлләү күздә тотыла. Әйтергә кирәк, әлеге күпер – юлның сигезенче этабындагы гына түгел, бәлки барлык күперләрнең иң озыны (3362 метр). Узган атнада Россия Президенты Владимир Путин Мәскәү – Казан М12 юлының Мәскәүдән Арзамас шәһәренә (Түбән Новгород өлкәсе) кадәрге өлешен ачты. Декабрь ахырында исә әлеге юл аша инде башкаладан Казанга кадәр барып җитәргә мөмкин булачак. Моның өчен элеккечә – 12 сәгать түгел, ә нибары 6,5 сәгать вакыт исраф ителәчәк.

Гүзәл затлар хакына

Татарстанда 2023–2026 елларда хатын-кызларны яклау-саклау һәм кайгырту максатындагы гамәлләрне тормышка ашыру чаралары планы расланган. Илкүләм гамәлләр стратегиясе кысасындагы боерыкка Премьер-министр Алексей Песошин кул куйган.

План тулаш-ханымнарның сәламәтлеген саклау, җәмгыятьне үстерүдәге ролен арттыру, социаль баткаклыкка эләгүләрен булдырмау чараларыннан тора. Анда тормышта авыр хәлләрдә калган хатын-кызларга ярдәм итү, йөклеләр өчен кризис үзәкләре ролен көчәйтү, балалы хатын-кызларга ярдәм итү өчен гаиләләрнең күпфункцияле үзәкләре челтәрен киңәйтү күздә тотылган. Рәхимсез мөнәсәбәткә дучар булган хатын-кызларга һәм кыз балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүне яхшырту, балаларның ышаныч телефонын популярлаштыру кебек мәсьәләләр дә каралган.

Моннан тыш шушы чорда Республика балалар клиник хастаханәсендә хатын-кызларның репродуктив сәламәтлеге мәктәбен булдырырга ниятләнелә. Аборт ясатудан баш тартучылар санын кимендә 15 процентка киметү планлаштырыла.

Шул ук вакытта кечкенә балалы аналар өчен өстәмә белем бирү программалары оештырылачак. Авылларда яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр түләү биреләчәк.

Өлкән яшьтәге хатын-кызлар да игътибардан читтә калмаячак. Аларга гериатрия ярдәмен көчәйтү, «Третий возраст» спартакиадасы, йөзү, өстәл теннисы ярышлары, башка чаралар үткәрү күздә тотыла.

Туризм

Иске яңа юл

«Бөек Идел юлы» төбәкара маршрутына илкүләм туристик маршрут статусы бирелде. Билгеле булганча, әлеге маршрут Идел буеның өч төбәген колачлый. Аңа Татарстан, Чувашия һәм Мари Эл керә. Бу маршрут кысасында туристлар Казан, Йошкар-Ола, Чабаксар һәм Зөя утрау-шәһәрчеген дә күрә ала.

Искә төшереп үтү зыян итмәс. Әлеге маршрут нигезендә тарихи Идел сәүдә юлы ята. Анысы инде, билгеле булганча, Бөек Ефәк юлының бер өлеше булып тора, төньяк өлеше санала. Яңартылган иске маршрут туристларга әлеге юлның Идел буе төбәкләре үсешендәге ролен күрсәтә һәм кабатланмас мәдәни һәм табигый истәлекле урыннары белән таң калдыра. Моннан тыш маршрут уза торган төбәкләрдәге милли традицияләрне, аш-су үрнәкләре белән танышу мөмкинлеген дә күздә тота. Экскурсия кысасында туристлар Идел елгасы буенча сәяхәт итә. Маршрут 500 чакрым озынлыктагы юлны үз эченә ала.

Әлеге мөмкинлектән киләсе елдан файдалана башларга була инде. Экскурсия кышын 3 көн һәм 2 төнгә исәпләнә, ә җәйге сезонда 4 көн һәм 3 төнне тәшкил итәчәк.

– «Бөек Идел юлы» төбәкара маршрутына илкүләм туристик маршрут статусы бирелүе туристлар санын арттырырга һәм яңа ярдәм чараларын җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк, – дип саный Россия Икътисадый үсеш министрлыгының туризмны үстерү департаменты директоры вазыйфаларын башкаручы Алимбәк Хидзев. – Әйтик, «Туризм һәм кунакчыллык индустриясе» илкүләм проекты кысасында төбәк грантка дәгъва итә ала.

Сүз уңаеннан, быел шундый 180 туристик инициативага ярдәм иткәннәр.

Россия туроператорлар ассоциациясе башкарма директоры Майя Ломидзеның да мондый статусның яңа мөмкинлекләр ачуына шиге юк.

– Төбәкләргә федераль дәрәҗәдә ярдәм чараларын, шулай ук туристлар агымын арттыру мөмкинлегенә ия була. Мондый маршрутларны сайлап алу критерийларының берсе – бәя һәм сыйфатның тәңгәл килүе, – ди ул.

Сүз уңаеннан

Максим РЕШЕТНИКОВ, Россия икътисадый үсеш министры:

– Чит ил туристлары Россияне яратсын өчен бик гади бер нәрсә эшләргә кирәк: алар безгә бер генә тапкыр булса да кунакка килергә тиеш. Мәсәлән, Көньяк-Көнчыгыш Азиядән килгән коллегаларыбыз, бер тапкыр Мәскәү, Петербург, Казан, Байкал, Ерак Көнчыгышта булганнан соң, үзләре өчен бөтенләй яңа дөнья ачтылар.

(Владивостоктагы Көнчыгыш икътисадый форумындагы чыгышыннан)

Сүзгә-сүз

Дмитрий ПЕСКОВ, Россия Президентының матбугат сәркатибе:

Әлегә Президент сайлауга үз кандидатурасын тәкъдим итү-итмәү турында берни дә әйтмәде. Әгәр Путин 2024 елда узачак сайлауга үз кандидатурасын тәкъдим итәчәк дип фаразласак, безнең илдә аңа беркемнең дә көндәш була алмаячагы көн кебек ачык. Аның халык арасындагы абруе бик зур мөмкинлекләр бирә һәм шул ук вакытта зур җаваплылык булып тора.

(РБКга биргән әңгәмәсеннән)

РОССИЯДӘ – ТКХ ХЕЗМӘТЛӘРЕ ӨЧЕН ТҮЛӘҮ

РИА Рейтинг мәгълүматларына караганда, илдә яшәүче гаиләләр узган ел акчаның уртача 10 процентын ТКХ хезмәтләре өчен түләүгә тоткан.

	Төбәк	ТКХ түләүләре өчен тотылган акча өлеше, %	Айлык сумма
1	Дагыстан	6,2	3604
2	Курск өлкәсе	6,6	3123
3	Севастополь	6,7	3389
...			
22	**Татарстан**	**9,1**	**4214**
...			
83	Чукотка АО	13,4	8356
84	Камчатка крае	13,5	9448
85	Магадан өлкәсе	13,7	9276
	Россия буенча	**10,0**	**5071**

Таксида йөрү кыйммәтләнгән

Август аенда республикада таксида йөрүнең уртача бәясе 1 километр юл өчен 29,67 сум тәшкил иткән. Росстат мәгълүматлары буенча, бәя июль аендагы белән чагыштырганда 10,5 процентка үскән.

«Реальное время» агентлыгы рәсми статистика мәгълүматларына таянып исәпләп чыгарганча, бер ел эчендә Татарстанда такси хезмәтенең уртача бәясе 32 процентка арткан. Узган елның августында 1 чакрым юл хакы 22,47 сум тәшкил иткән булган.

Ел башыннан бирле республикада таксида йөрүнең уртача бәясе 18,8 процентка арткан. Гыйнвар аенда 1 чакрым юл 24,97 сум торган.

Алтын көз килде

Бу атнада Татарстанда бераз яңгырлы җылы һава саклана. Гидрометеоүзәк хәбәренә караганда, чәршәмбе һәм пәнҗешәмбе – 13–14 сентябрьдә, атмосфера басымы зур булу сәбәпле, явым-төшем көтелми диярлек. Чәршәмбедә көньяк районнарда гына көндез бераз яңгыр булырга мөмкин. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +17...+22 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнге сәгатьләрдә +4...+11 градус.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматларына караганда, җомга һәм шимбә – 15–16 сентябрьдә җылы һава саклана. Көндез һава температурасы +18...+23 градус чикләрендә тирбәләчәк. Көндез явым-төшем ихтималы аз.



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КАРАБАХ ТИРӘСЕНДӘ УТ ЯГУ

Үткән атнада Кавказда вазгыять тагын кискенләште. Таулы Карабах тирәсендә күптәннән тынмый барган конфликт яңадан зур сугыш хәленә китереп терәлде. Бу юлы бәхәскә берничә зур дәүләтнең катнашып китү ихтималлыгы артты. Исегезгә төшерәбез: 2020 елның көзендә Баку һәм Ереван мөнәсәбәтләрне зур кораллы конфликт ярдәмендә ачыклады. Азәрбайҗан армиясе, технологик яктан яхшырак корал кулланып, әрмәннәрне чигенергә мәҗбүр итте, байтак стратегик торак пунктларны үз контроленә алды. Халыкара җәмәгатьчелек азәрбайҗанлыларга каршы килә алмый иде, чөнки төбәк рәсми рәвештә алар җире булып санала. Бу Карабах сугышына азатлык сугышы сататусы бирә. Ереван ярдәмгә ОДКБ көчләрен чакырып карады, әмма сугыш Азәрбайҗан территориясендә барганлыктан, башында Мәскәү торган күмәк көчләр булыша алмады, чөнки хәрби ярдәм күрсәтү бу очракта Уставка туры килми иде. Төбәккә танклар белән бәреп керү зур сугыш вәгъдә итә: Азәрбайҗанны Төркия һәм Израиль яклый иде. Әрмәннар белән исә Иран аркадашлык итә. Бик катлаулы төен төйнәлгән урын бу. 2020 елның 10 ноябрендә Азәрбайҗан, Әрмәнстан, Россия катнашында Таулы Карабахта сугышны туктату турында килешү төзелде. Шуннан соңгы елларда Баку һәм Ереван, конфликтның даими пыскып торуына карамастан, Тыныч килешү имзалауга якынлаштылар. Әмма Әрмәнстанда бу килешүгә каршы көчләр шактый иде. Үткән атнада Карабахта сепаратчы көчләр «Президент сайлавы» үткәрделәр, ул сайлауны беркем дә танымады. Хәтта Пашинян да җиңүче «Президент»ны котларга җөрьәт итмәде.

Рәсми Ереван, Мәскәүдән һәм ОДКБдан өметен өзүен игълан итеп, Америка белән якынаерга ниятләде. АКШ – Әрмәнстан хәрби өйрәнүләре булачагы турында сүз таратты. Мәскәүгә бу ошамады. Коллизияләр шул дәрәҗәдә куерды: Әрмәнстандагы «Вагнер» сугышчылары дәүләт түнтәрелеше әзерли дигән вәсвәсә калкып чыкты.

Азәрбайҗан үз гаскәрләрен Әрмәнстан чигенә китерде. Иран армиясе дә Азәрбайҗан чигенә якынайтылды дигән хәбәрләр таратылды. Соңыннан рәсми Тәһран һәм Баку аларны «фейк» дип игълан иттеләр. Әмма Әнкара, Иран Азәрбайҗанга каршы көч кулланса, Төркиянең җавабы кичекмәстән булачак дигән рәсми белдерү ясады. Пакьстанның Тышкы эшләр министрлыгы, сугыш башланса, Исламабад Баку ягында булачак, чөнки Иран Әрмәнстанны яклый дигән белдерү белән чыкты. Хәрби транспорт самолетлары Израильдән Бакуга корал ташый дигән хәбәрләр дә килә. Сизәсездер: зур сугыш уты кабыну ихтимал. Соңгы сәгатьләрнең хәбәрләре конфликт сөйләшүләр өстәлендә хәл ителер дигән өмет уята, ләкин хәвеф бетмәде әле.

Россиядә

КАЗНАГА АКЧА ТУЛГАНДА

Долларның һәм нефтьнең җитәкләшеп кыйммәтләнүе Россия бюджетына уңай тәэсир итте. Шул дәрәҗәдә уңай тәэсир итте: федераль хөкүмәт Рәисе Мишустин: «Россия бюджетының нефть-газ керемнәре үткән елгыдан сизелерлек артык», – дигән белдерү ясады. Шулай булгач, бюджет дефициты төгәлләнә. Дефицитның кимүе турында хөкүмәтнең финанс блогыннан да хәбәрләр алына. Сөенечлеме? Сөенечле. Ләкин хәбәрнең яхшы ягы шуның белән бетә. Казнага акча безнең кесәләрдән ява. Бензинның көннән-көн кыйммәтләнүе турында сөйләп торасы юктыр. Бензин валюта кыйммәтләнсә дә, кыйммәтләнмәсә дә, нефть бәясе үссә дә, үсмәсә дә кыйммәтләнде һәм кыйммәтләнәчәк. Моңа без шикләнмибез, яңа Россиядә утыз елдан артык яшәү тәҗрибәбез бар. Мотор ягулыгының чималы да, заводы да үзебездә, шулай булгач, доллар аңа указ түгел… кебек. Ягулык башка товарлар инфляциясен алга этәрә. Доллар да инфляциягә булыша. Инфляциягә каршы көрәшеп, Үзәк банк та төп ставканы күтәрә һәм икътисад тәгәрмәченә күсәк тыга.

Бәяләр күтәрелү сәбәплеме, башка сәбәпләр беләнме, 15 миллионлап россияле тирән депрессия хәлендә, ди Стратегик инициативалар агентлыгы (АСИ). АСИ – Россия Хөкүмәте тарафыннан төзелгән оешма, оппозициядә түгел, дип әйтүем. Рәсми статистикага бәйле мондый оешмаларның саннарны каян алуы миңа сер. Кесәмдә Россия паспорты йөрсә дә, миңа психологик халәтем турында беркем дә сорау бирмәде. Хатыныма да, гаиләмә дә, танышларыма да. Шулай булгач, саннар каян килә? Мин депрессиядә түгел. Хезмәт хакының картадан алганчы ук эреп бетүенә юмор белән карыйм, төшенкелек өчен сәбәп дип санамыйм. Илдәге икътисадый һәм сәяси хәлнең чайкалып торуы шатландырмый, билгеле. Премьер-министр Мишустин әфәнде дә вазгыятьнең бүген уңай булуына аркаланып, киләчәккә өметле фаразлар ясамаска чакырды. Иртәгә ни буласын белеп булмый. Россия төбәкләре әнә, көч структуралары бюджетын рекордлы темплар белән үстерәләр, ди. Беренче яртыеллыкта төбәк бюджетлары «силовик»ларны финанслауны 53,4 процентка арттырган. Дөрес, «силовик»ларны нигездә федераль хөкүмәт финанслый, әмма төбәкләр дә үзләренең өлешен уртак казанга сала.

wallpapers.com

ОЗЫН ЮЛНЫҢ КЫСКАСЫ

Нәтиҗә

Җырыбыз да охшаш, юлыбыз да. Казанда узган «РОСТКИ» халыкара форумында татарлар белән кытайларның уртак тел табуының серен чиштеләр. Хәзерге шартларда ике ил арасындагы хезмәттәшлекне үстерүнең әһәмиятен билгеләделәр. Ә иң мөһиме – республикада башланган эшнең дәвамлы булачагын әйттеләр. Кытайга юл Татарстан аша салыначак.

«Татар-информ»

Синьцзян-Уйгыр автономияле районы Хөкүмәте Рәисе урынбасары Мәрдан Мукийит сүзләренә караганда, уртак максат – үзара файдалы һәм бер-беребезне тулыландырыла торган хезмәттәшлек. «Тырышлыгыбыз белән эшлекле элемтәләребезне үстерүнең яңа юлларын билгели алачагыбызга ышанабыз», – диде ул.

Өчпочмаклы җыен

– Без Россия һәм Кытай башлыкларына төбәк дәрәҗәсендәге хезмәттәшлеккә ярдәм күрсәткәннәре өчен рәхмәтле. Әлеге шартларда «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара файдалы хезмәттәшлек» форумы күпсанлы юнәлешләр буенча уртак эшчәнлекне көчәйтү мөмкинлеген тәэмин итүче үзенчәлекле мәйдан булып тора, – диде Рөстәм Миңнеханов форумның пленар утырышында.

Тимерне кызуында сугып, Рәис республикада башланган эшне дәвамлы итү теләген дә белдерде.

– Киләсе елда форумның датасын 14–15 ноябрьгә билгеләргә тәкъдим итәбез һәм Кытайдагы хезмәттәшләребезне икенче Халыкара җыенда түземсезлек белән көтәбез, – диде ул.

Алга китеп булса да әйтик: форумның ачылыш тантанасында яңгыраган әлеге тәкъдим турында җыен азагында хәл ителгән мәсьәлә кебек сөйләштеләр инде. Казанда Халыкара форум киләсе елда да узачак.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, Татарстан үз дәрәҗәсендә Россия – Кытай хезмәттәшлеген үстерүгә өлеш кертергә тырыша. Узган ел нәтиҗәләре буенча, ике арада сәүдә әйләнеше 1,6 миллиард доллар тәшкил иткән. Үсеш – 58 процент. «Әлеге күрсәткеч артуын дәвам итә, быелның беренче яртысында Татарстан белән Кытай арасында 740 миллион сумлык товар сатылган», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Форум кысасында узган матбугат очрашуында Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе Талия Миңнуллина ел йомгаклары буенча әлеге күрсәткеч 2 миллиард долларга җитәчәк дип тә фаразлады. Форум да элемтәләрне нығытуда җитди адым булырга тиеш. Кунакларның игътибарын, шул исәптән республиканың сәүдә-сәнәгать мөмкинлекләре тәкъдим ителгән «Russia – China Expo» күргәзмәсе һәм эшлекле очрашулар белән генә түгел, ә чын татарча мәтрүшкәле чәй һәм өчпочмак белән дә җәлеп итәргә тырыштылар. Дөрес, әлегә ике арадагы килешүләр турында сөйләргә иртәрәк, диде Талия Миңнуллина. Әмма өмет зур. Халыкара форумга Кытайдан 200ләп компания вәкилләре килгән.

– Ике илнең бизнес даирәләре тәкъдиме белән уздырыла торган әлеге җыен дәүләтләребез һәм аларның төбәкләре арасында киң колачлы, тигез хокуклы, ышанычлы партнерлык һәм стратегик хезмәттәшлекнең алга таба үсүенә ярдәм итәчәк, ике яклы сәүдә-икътисадый, фәнни-техник, мәгариф, мәдәни һәм гуманитар мөнәсәбәтләрнең барлык якларына да кагылачак, – диде җыен кысасында узган «Сәяси партияләрнең үзара хезмәттәшлеге – халыкара мөнәсәбәтләрнең мөһим өлеше» дип аталган «түгәрәк өстәл»дә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе, Россия Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары буенча комиссиясе рәисе Фәрит Мөхәммәтшин.

Әйткән сүз – аткан ук

Россия тышкы эшләр министры Сергей Лавров фикеренчә, Россия белән Кытай арасындагы хезмәттәшлек моңарчы күрелмәгән дәрәҗәгә җиткән.

– Ул бүген илләр арасындагы хезмәттәшлек үрнәге булып тора, – диде министр форумның пленар утырышында катнашучыларны видеоэлемтә аша сәламләгәндә.

Чарада катнашкан Россия икътисадый үсеш министры Максим Решетников әйтүенчә, соңгы ике елда Россия белән Кытай арасында сәүдә әйләнеше ел саен өчтән бергә артып бара.

– Быелның җиде ае нәтиҗәләре буенча үсеш 30 проценттан да күбрәк тәшкил итә. Бу – быел ике арадагы сәүдә әйләнеше 200 миллиард долларлык күрсәткечкә җитәчәге һәм аннан да күбрәк булачагы турында сөйли, – диде ул.

Мәскәү кунагы Россия белән Кытай арасындагы мөнәсәбәтләр яңа дәрәҗәгә чыгуын да әйтте. Бер генә сан: агымдагы елның беренче яртыеллыгы нәтиҗәләренә караганда, Россиягә чит илдән кертелгән товар күләме 79 процентка арткан. Импортның 60 проценты диярлек машина техникасына туры килә.

– Бу елның мартында ике ил җитәкчеләре хезмәттәшлекнең стратегик юнәлешләрен билгеләде, шул рәвешле эшкә яңа тизлек бирделәр, – диде Максим Решетников.

Министр телгә алган очрашуның ни дәрәҗәдә әһәмиятле булуын Талия Миңнуллина да әйтте.

– Кытай Халык Республикасы Рәисе безнең илгә килгәч, Россия Президенты Владимир Путин һәм Си Цзиньпин икътисадый хезмәттәшлекне үстерүгә бәйле уртак белдерү белән чыгыш ясадылар. Алар шул исәптән төбәкара хезмәттәшлекне үстерү турында да әйтте. «РОСТКИ» халыкара форумы әнә шул максатка ирешүне күздә тота. Шунысын да искәртик: форум ниндидер зур сәяси очрашулар урыны түгел, бу – бизнес өчен уңайлы мәйдан, – диде Татарстан Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе.

Форум алдан фаразлаганнан уңышлырак килеп чыгуын да искәртте ул.

– Җыенны оештырганда биредә 3 мең чамасы кеше катнашачак дип фаразлаган идек. Форумга рәсми рәвештә теркәлүчеләргә күз салсак, әлеге сан ике тапкыр зуррак. Халыкара җыенда илнең 50дән артык төбәгеннән вәкилләр катнаша. Безгә 20ләп чит илдән килерләр дип тә уйламаган идек. Бу – Россия белән Кытай арасындагы мөнәсәбәтләр башка илләрне дә кызыксындыра дигән сүз. Шуңа күрә «РОСТКИ»да утырткан үсентеләр һичшиксез үз җимешен бирәчәк дип уйлыйбыз. Тагын 2–3 елдан ул куәтле мәйданга әвереләчәк, – диде Талия Миңнуллина.

Рөстәм Миңнеханов татарлар белән кытайларны нәрсә берләштерүен дә әйтте.

– Безнең җырлар пентатоникага корылган, аларның яңгырашы охшаш. Димәк, кайчандыр тамырларыбыз кисешкән булган. Без моны эштә дә тоябыз. Безгә үзара аңлашу, уртак тел табу җиңел. Пандемия бераз тоткарлады, әмма хәзер беркем дә туктата алмаячак. Безнең юл фәкать Кытайга таба гына юнәлгән, – диде ул, форумга йомгак ясап.

Эльвира ВӘЛИЕВА

Хокук турында сөйләшү



tatarstan.ru

Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Азия илләре омбудсменнары ассоциациясенең Директорлар советы әгъзалары белән очрашты. Татарстанга алар ассоциация Генераль Ассамблеясының утырышын уздыру һәм «Омбудсменнарның нәтиҗәле эше: милли үзенчәлекләр һәм универсаль чаралар» халыкара фәнни-гамәли конференциясендә катнашу өчен килде.

Фәрит Мөхәммәтшин хокук яклаучыларны Татарстан Рәисе һәм дәүләт хакимияте органнары исеменнән сәламләп: «Республиканың Россия белән ассоциация арасындагы хезмәттәшлекне алга таба үстерүгә лаеклы өлеш кертәчәгенә ышанам», – диде.

«Татарстанда Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил институты белән тыгыз элемтәләр урнаштырдык. Республикада вәкаләтле вәкилнең законнар тәкъдим итү хокукына ия булуы мөһим. Депутатлар, омбудсмен белән бергәләп, кешеләрнең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклый. Бу исә халыкның хакимият органнарына ышанычы тагын да артуга китерә», – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Азия илләре омбудсменнары ассоциациясе президенты Әҗас Әхмәд Курәши, үз чиратында: «Азия омбудсменнар ассоциациясе үз эшчәнлегендә өлгереп җитте, һәм ул даими үсә», – дип билгеләп үтте.

Азия омбудсменнар ассоциациясе 1996 елның 16 апрелендә сәяси булмаган бәйсез оешма сыйфатында оештырылган. Максаты – хокукларны саклау-яклау мәсьәләләрендә тәҗрибә алышу. Аңа Азиянең 25 иленнән (Пакьстан, Азәрбайҗан, Иран, Кытай, Япония, Малайзия, Индонезия, Һиндстан, Грузия кебек илләр) 44ләп әгъза керә.

Депутатлар игътибарына!

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының «Татарстан Республикасы Рәисенең республиканың эчке һәм тышкы хәле турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык Юлламасы» мәсьәләсе буенча кырык алтынчы утырышы 14 сентябрьдә Сәйдәш исемендәге Дәүләт Зур концертлар залында (Ирек мәйданы, 3 йорт) үткәрелә. Утырыш 10.00 сәгатьтә башлана.
Дәүләт Советының кырык җиденче утырышы 14 сентябрьдә Дәүләт Советының утырышлар залында (12.00 сәгатьтә башлана) уздырыла.
Депутатлар Дәүләт Советының кырык алтынчы утырышына – 14 сентябрьдә Дәүләт Зур концертлар залында 8.00 сәгатьтән башлап, кырык җиденче утырышка – 14 сентябрьдә Дәүләт Советы бинасында 11.00 сәгатьтән башлап теркәләчәк.
Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Ватан хакына

НАМУС ЭШЕ

Улым белән горурланам! Батыр егет үстергән Венера Мөбарәкшина улының Казан танк училищесына укырга керүенә әнә шулай сөенә дә, шул ук вакытта борчылуын да яшерми.

– Улымны үгетләп карадым, әмма ахыр чиктә бу теләгенә каршы килмәдем. Мин аның белән горурланам. Мин үзем дә хәрбиләр гаиләсендә тәрбияләнеп үстем, хәрби частьта дөньяга килдем. Мөгаен, бу кан белән күчәдер. Улым Альберт инде икенче сыйныфта укыганда ук җитди карарга килде. Сәгать алтыда торып, өч чакрым йөгерә, мин шулай армиягә әзерләнәм, ди иде, – ди Венера ханым, күз яшьләрен сөртеп.

Шимбә көнне Альберт җаваплы юлны сайлаган иптәшләре белән бергә хәрби ант бирде. Кыю егетләрне котларга якыннары, туганнары, дин әһелләре җыелган иде. Казанның танк училищесында узган тантаналы чарада Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

Парламент Рәисе бу вакыйганы курсантлар тормышындагы иң мөһим мизгелләрнең берсе дип атады.

– Хәрби ант бирү – Ватанга тугры булырга тантаналы рәвештә ант итү ул. Сезгә хәрби фәнне, техника һәм коралларны өйрәнү, армиянең Ватанны саклауга әзерлеген тәэмин итү буенча зур җаваплылык йөкләнә, – диде ул, егетләрне котлап.

Фәрит Мөхәммәтшин танк гаскәрләренең Бөек Ватан сугышында, Әфганстанда, Төньяк Кавказда хәрби бурыч үтәгәндә, махсус хәрби операциядә зур батырлык күрсәтүен дә искәртте.

– Хәзерге Ватанны саклаучылар электән килгән традицияләрне лаеклы рәвештә дәвам итә, илнең оборона мөмкинлекләрен ныгытуга зур өлеш кертә, – диде парламент Рәисе. – Уку барышында курсантлар хәрби белем генә алып калмый, үзендә Россия офицерына хас сыйфатларны да булдыра. Сез танк училищесында урнашкан күркәм традицияләрне лаеклы рәвештә дәвам итәрсез дип өметләнәм.

Казан хәрби танк училищесының тарихы, дөрестән дә, бик бай. Горурланып сөйләрлек уңышлары да байтак. Биредә белем алып чыккан 70 егет – Советлар Союзы Герое, дүртесе – Социалистик Хезмәт Герое, 15е Россия Герое дигән дәрәҗәле исемгә лаек булган. Әлеге уку йортын тәмамлаган 250 егет исә генерал дәрәҗәсенә күтәрелгән.

tatarstan.ru

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ПАВЛОВ АЛЕКСАНДР ФИЛИППОВИЧ

(25.06.1938–09.09.2023)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсенең элекке генераль директоры Павлов Александр Филиппович 9 сентябрь көнне 86 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Александр Павлов 1938 елның 25 июнендә ТАССРның Питрәч районы Надеждино авылында дөньяга килә. Хезмәт эшчәнлеген, Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң, 1960 елда Казан моторлар төзү заводының механика цехында шомартучы вазыйфасында башлап җибәрә. Эштән аерылмыйча, Казан авиация техникумын һәм авиация институтын тәмамлый.

1970 елда цех начальнигы итеп билгеләнә. Шуннан соң заводта барлык һөнәри үсеш баскычлары аша уза: производство башлыгы урынбасары, производство башлыгы, директорның производство буенча урынбасары, баш инженер вазыйфаларында хезмәт куя.

1983 елда ул Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсенә җитәкче итеп билгеләнде һәм 21 ел буе завод директоры булды.

Александр Филиппович җитәкчелегендә предприятиене үстерүгә зур этәргеч биргән киң колачлы кайбер проектлар тормышка ашырылды. Җитештерелә торган авиация техникасының, башка техниканың мөмкинлекләрен, ышанычлылыгын арттыру буенча зур эшләр башкарылды. Машина төзү производствосы яңартылды, НК-8-2У, НК-8-4, НК-86 эшләнмәләрен җитештерү күләмнәре артты.

Александр Павлов болгавыр 1990 нчы елларда КМПОны яңа икътисадый шартларга җайлаштыруга ирешә. Моторлар төзү берләшмәсе төп продукциядән, газ турбиналы двигательләрдән тыш, автобуслар, авыл хуҗалыгы техникасы өчен кирәкле детальләр җитештерә башлады.

Ул заводта эшләүчеләрнең социаль мәсьәләләрен хәл кылуга җитди игътибар бирде. Торак кварталлар, мәдәни-спорт корылмалары, дәвалану-савыктыру объектлары төзелде.

Александр Павлов XI чакырылыш Татарстан АССР Югары Советы депутаты, XII чакырылыш Татарстан АССР халык депутаты итеп сайланды.

Александр Филипповичның күпьеллык нәтиҗәле хезмәте югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» IV дәрәҗә ордены һәм «Дуслык» ордены, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале, «Хезмәттәге батырлык өчен», «Фидакарь хезмәт өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы оештырылуга 100 ел» медальләре, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатлары. Шулай ук аңа «СССРның мактаулы авиатөзүчесе», «ТССРның атказанган машина төзүчесе» дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Александр Павлов югары дәрәҗәдә һөнәри осталыгы, үзенә һәм үз буйсынуындагыларга карата таләпчәнлеге, иҗтимагый бурычка тугрылыгы белән аерылып торды. Эшлекле сыйфатлары һәм кешелеклелеге, яраткан эшенә, һөнәренә тугрылыгы, кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе коллегалары арасында һәм җәмәгатьчелектә зур абруй-хөрмәткә китерде.

Александр Филиппович Павловның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә саклаһыр.

Р.Н. МИҢНЕХАНОВ, М.Ш. ШӘЙМИЕВ, Ф.Х. МӨХӘММӘТШИН, А.В. ПЕСОШИН, Ә.Ә. СӘФӘРОВ, О.В. КОРОБЧЕНКО, И.Р. МЕТШИН, М.П. АФАНАСЬЕВ, И.М. КАШАПОВ, А.П. ЛАВРЕНТЬЕВ, Ш.Р. АГЕЕВ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президумы, X чакырылыш (1980–1985), XI (1985–1990) һәм XII (1990–1995) чакырылыш Татарстан АССР Югары Советы депутаты, «Казан моторлар төзү-җитештерү берләшмәсе» акционер җәмгыяте генераль директоры (1983–2004)

ПАВЛОВ
Александр Филиппович

кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Илебез сәнәгатенең төп эшлеклеләреннән берсе, игътибарлы, көчле җитәкче, җаваплы депутат, үз эшенең остасы арабыздан мәңгегә китте.

Павлов Александр Филипповичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

ӨЙРӘТМИЛӘР МӘКТӘПЛӘРДӘ

БЕЛЕМ ЙОРТЫНДА БАЛАНЫ НӘРСӘ КӨТӘ?

Борчыган мәсьәлә

Мәктәп бусагасын атлап керү балага шатлык кына түгел, стресс та. Кызыксынулары да, дөньяга карашлары да төрле булган балаларны бик үк күңелле булмаган күренешләр дә сагаларга мөмкин. Шуларның иң киң таралганнарын барлап, балаларны саклау-яклау өчен ата-аналарга нишләргә кирәк икәнен ачыкладык.

Мәктәп кайчан газап була?

Статистика буенча, мәктәп укучыларының 20–50 проценты яшьтәшләре тарафыннан эзәрлекләүләргә дучар ителә. Фәнни тел белән әйткәндә, буллинг бу. Буллинг корбаннарын табу җиңел түгел. Ник дигәндә, бу хакта ачылып сөйләү күңелле эш саналмый. Шулай да башларыннан узганнар белән уртаклашучылар (исемнәрен үзгәртү шарты белән, билгеле) табылды.

– Мин мәктәпкә укырга кергәндә таза кыз идем. Нәселдән дә киләдер, безнекеләр барысы да – эре сөякле. Әмма бала-чага яшендә моны кимчелек итеп кабул итәсең бит инде, – дип сөйләде хәзер инде икътисадчы булып эшләүче Әлфия. – Классташларымның күпчелеге малайлар иде. Иптәш булырдай кызлар да юк диярлек. Ә малайларның теле ачы борыч белән бер. Нинди генә сүзләр яудырмадылар инде! Укытучыга барып зарланганым да булды хәтта. Әмма бер тапкыр да кайтып еламадым. Хәзер генә ул ата-аналар балалары өчен мәктәпкә барып ниләр генә эшләми. Без укыганда алай түгел иде.

Классташ егетенең бер сүзе аеруча күңеленә тия Әлфиянең. «Сине үскәч берәү дә кияүгә алмаячак, чөнки син фил кадәр», – дигән иде ул. Иң кызыгы – 11 нче сыйныфны бетергәндә бергә вальс биедек. Филләр онытылган иде инде ул чакта. Классташлар очрашуында да бу сүзләре өчен гафу үтенде. Сыйныфтагылардан иң беренче булып мин гаилә кордым. Хәзер инде ул кадәр таза түгелмен. Студент чакта ябыктым, махсус залга йөрдем», – дип сөйләде ул.

Мәктәп яшендәге балалар тагын нинди тискәре күренешләргә бирелергә мөмкин?



1. Шутинг
2. Наркотиклар сатуга чакыру
3. Деструктив төркемнәр
4. Токсикомания (сниффинг)
5. Хәмер эчү
6. «Мәктәпкә – мәктәп», «төркемгә – төркем» сугышулар

Хәзерге көндә Казанда яшәүче Рамилә исә буллинг корбаны түгел, сыйныфташын эзәрлекләүчеләрнең берсе булган.

– Яшермим: безнең сыйныфта төрле гаиләләрдә тәрбияләнгән балалар укыды. Мин хәллерәк гаиләдән идем. Шундыйлар белән берләшеп, башкаларны рәнҗеткән чаклар булды, – дип искә ала ул. – Сүз дә юк, мин бу гамәлләрем өчен хәзер шулкадәр үкенәм! Миңа бик оят. Хәтерлим: әтисез үскән, әнисе дә район үзәгендә кибетче булып эшләгән бер кыздан аеруча көлә идек. 1 сентябрьгә барыбыз да яңа кием-салым, букча тотып киләбез. Ә аның гел бер сәләмә кием. «Кара, минеке нинди матур!» – дип, аның каршына басып, яңа күлмәгем белән мактанганым истә. Әйтәм бит, хәзер боларны искә алу йөрәгемә кылыч кадаган кебек. Бала-чага шулкадәр усал була белә икән, дим. Әле гаиләм юк. Әмма балаларыма буллингның, башкаларга өстен карауның ни дәрәҗәдә дөрес түгел икәнен һичшиксез аңлатачакмын. Шунысына да аптырыйм: ник әти-әни, укытучылар бер сүз әйтмәгән икән? Хәер, ул кыз бездән зарланмады да бугай инде…

Саннар ни сөйли?

Әңгәмәдәшләрнең: «Бала-чага усал да була белә икән», – дигән сүзен саннар да раслый.

2022 ел ахыры – 2023 ел башына 49 меңнән артык бала мәктәптә контрольгә алынган икән. Бу алдагы еллар белән чагыштырганда 8–10 тапкыр күбрәк. Аерым игътибар таләп ителгән укучыларны махсус «тамгалыйлар» да әле. Әйтик, яшел зона (укуда калышучылар, гадәттә, имин булмаган гаиләләрдән), сары зона (дәресләрне калдыручылар, тәртипсезләр), кызыл зона (усал балалар, ПДН игътибарындагылар).

Республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең еллык хисабындагы мәгълүматларга ышансаң, 2022 елда кабул ителгән мөрәҗәгатьләрнең 1758е яшьтәшләре эзәрлекләвенә бәйле булган.

Белгеч сүзе

Практик психолог Зөһрә Кәримова әйтүенчә, балаларның мәктәптә төрле тискәре күренешләр белән очрашуына күп нәрсә сәбәпче була ала.

– Буллинг, төрле төркемнәр йогынтысыннан тыш, балаларның 3 ай дәвамында бер-берсе белән очрашмавы, башка дуслар табуы, кемнеңдер каядыр ял итүе, нидер эшләве көнчелек уятырга мөмкин, – ди белгеч. – Мондый очракта ата-аналарга баласы белән сөйләшергә генә кала. Аның көне ничек узган, бүген ул нинди яңалык белгән.

ru.freepik.com

Психолог әйтүенчә, буллинг ише күренешләр баланың үз-үзенә ышанычын киметә. Мондый вакытта ата-анага бигрәк тә терәк-таяныч булырга кирәк. Баланың хис-кичерешләрен уртаклашу зарур. Психология телендә бу «хисләрне контейнерга салу» дип атала.

Зөһрә Кәримова баланың кызыксынулары хакында даими сорашып торырга куша. Чөнки бүген яраган иртәгә инде искергән булырга да мөмкин. Бала белән элемтәне югалтмас, бер дулкында булу өчен дә мөһим бу.

– Балага булышам дисәң, аны күзәтергә кирәк. Контроль турында түгел сүз. Хисләрен, эмоцияләрен күзәтергә. Еш кына балаларның төрле төркемнәргә кушылуы авторитетлы кешеләрнең – ата-ана, якыннарның аларның тормышында катнашмавыннан башлана, – дип аңлатты белгеч.

Нәфрәт белән түгел, мәхәббәт белән яшәүче балалар явыз булмаячак. Монысы – республикада Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Ирина Волынец фикере. «Әгәр мәктәптә бала үзен агрессив тота икән, димәк, аның өендә барысы да яхшы түгел. Мәхәббәт һәм игелек белән яшәүче бала үзенең агрессиясен яшьтәшләренә чыгармас», – ди ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЯШЬЛӘР «ТЕЛ»Е
Яшьләр телен аңлыйм дисәң, аерым сүзлек кирәк. Балагызның шундый сүзләр кулланганы бардыр бит?

Агриться >> ачулану, усаллану
Бэсти >> якын дус
Вайб >> мохит, халәт
Зашквар >> оят, хурлык булырдай эш
Кринж >> башка кешенең эш-гамәлләре өчен оялу
Криповый >> куркыныч
Пруф >> дәлил
Рандом >> очраклы
Рофл >> мәзәк хәл
Факап >> уңышсызлыкка дучар булу
Бумер >> хәзерге чынбарлыкны кабул итәргә теләмәгән кешеләрне (40 яшьтән башлап) шулай атыйлар
Днокл >> классташ
Нуб >> нинди дә булса эштә яңа кеше, тәҗрибәсез
Рил ток >> чынбарлыкка туры килгән хәбәр, мәгълүмат
Сигма >> үз-үзенә ышанган кеше (гадәттә, ир-егет)
Флексить >> масаю, мактану

КЫРЫННЫҢ АХЫРЫ КЫЕН

Елга бер тапкыр бирелә торган 45 мең сумлык пособиене рәсмиләштерергә ярдәм итәбез! Соңгы арада мошенниклар «Телеграм» аша халыкны әнә шундый вәгъдәләр белән төп башына утырта башлаган. Ышанычны яулау ысулын да тапканнар. Ялган телеграм-каналларын Дәүләт хезмәтләре порталы дип атаганнар.

Әлеге телеграм-канал, дөрестән дә, беренче карашка ышаныч тудыра. Логотибы да нәкъ чын порталдагысы кебек. Каналны оештыручылар тиз арада, бернинди мәшәкатьсез генә яңа төр пособиеләр рәсмиләштерергә дә «ярдәм итмәкче». Күпләр әнә шул буш вәгъдәгә «каба» да инде. Әмма әлеге каналга керү өчен махсус төймәгә баскач, автомат рәвештә ике сылтама аша күчәсең дә телефонга вируслар кереп оялаганын сизми дә каласың. Аның аша мошенниклар онлайн банкны «җимереп», картадагы акчаңны да урлый ала, дип кисәтә белгечләр.

Юрист Илнур Галимуллин сүзләренә караганда, соңгы арада мошенниклар иң ышанычлылардан саналган Дәүләт хезмәтләре порталын күпләп үз максатларында куллана башлаган.

– Әле күптән түгел генә алар кешегә шалтыратып, Дәүләт хезмәтләре порталындагы парольне үзгәрткәнме-юкмы икәнлеге белән кызыксына иде. Аны портал операторы дип белеп, барлык пароль-логиннарын әйтүчеләр күп булды. Мошенниклар, үз чиратында, Дәүләт хезмәтләре порталындагы бөтен мәгълүматны кулланып, кеше исеменә микрофинанс оешмаларында кредит рәсмиләштерә ала. Шул рәвешле төп башына утыручылар шактый булды, – ди юрист. – Шуңа күрә гади генә кагыйдәне истә тотарга: таныш булмаган номерларны алмаска, чит кешеләргә үзегез турында шәхси мәгълүматны әйтмәскә кирәк. Дәүләт хезмәтләре порталы операторлары кешегә беркайчан да шалтыратып, мәгълүмат сорамаячак, «Телеграм» аша да эш итмәячәк.

«Телеграм» дигәннән, соңгы арада мошенниклар аның аша үзләренең кырын эшләренә үсмерләрне дә күпләп җәлеп итә башлаган. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, мошенникларга ярдәм итүче арадашчылар арасында хәзер яшьләр, хәтта балигъ булмаганнар да очрый башлаган. Аларга, нигездә, курьер буларак эшләргә тәкъдим итәләр икән. Алар, мошенник корбаныннан акчаны алып, аны кырыгалдарга илтеп тапшырырга тиеш була. «Шуңа күрә эш тәкъдим иткән белдерүләрдә нәрсәнедер илтеп биргән, алып кайткан өчен бик зур акча вәгъдә итсәләр, шикләнергә кирәк», – дип кисәтәләр министрлыкта.

– Яшьләрне тиз арада күп итеп акча эшләп алу мөмкинлеге кызыктыра. Өстәвенә мошенниклар сине, бернинди зыяны булмаячак, дип ышандыра. Аларга хәтта корбаның белән үзеңне ничек тотарга, ничек сөйләшергә икәнлеге төгәл аңлатылган инструкция дә бирәләр, – ди Илнур Галимуллин. – Әмма үсмерләр мондый кырын эшкә ризалашыр алдыннан шунысын белсен иде: мошенникларның эзенә төшәр алдыннан, кагыйдә буларак, иң элек арадашчыларны, шул ук курьерларны тоткарлыйлар. Закон нигезендә хәзер алар да җинаять җаваплылыгына тартыла. Аларга эш бирүчеләр еш кына чит илдә яшәп, эш итеп яткан була. Шуңа күрә матди зыянны кире кайтару бурычы да еш кына арадашчылар җилкәсенә төшә. Яше тулмаган булса, бала өчен моны ата-анасына эшләргә туры киләчәк.

Мошенниклар үсмерләрне аулауның башка юлларын да таба. Күптән түгел «Росгосстрах» оешмасы бу уңайдан махсус сораштыру уздырган. Аның барышында мәктәп укучыларының 76 проценты телефон аша мошенниклар белән аралашып караганы булганын әйткән. Яшь респондентларның 21 проценты исә социаль челтәрләрдә таныш булмаган сәер кешеләрдән ярдәм сорап язган смс-хәбәрләр алуын әйткән.

pixabay.com

Педагог-психолог, балалар психологы Регина Фәхрисламова фикеренчә, замана балалары бик инфантиль, шуңа күрә алар мошенниклар тозагына бик җайлы кабалар да.

– Хәзерге балалар бу тормышта бар нәрсә дә җиңел бирелә дип уйлый. Бер яктан, моңа гаҗәпләнәсе дә юк кебек. Бүген көндәлек тормышыбызда «җиңел акча» дигән төшенчә адым саен очрый, аны гадәти күренеш итеп тәкъдим итәргә тырышалар бит. Бала да шуны күреп үсә, – ди белгеч. – Аннары хәзерге балаларның күбесе начар гамәл кылсаң, аның өчен җәзасы булачагын белмичә үсә. Чынлыкта бала үз хаталарында өйрәнергә тиеш. 9 яшендә инде бала бу кагыйдәне тулысынча аңына сеңдергән булырга тиеш. Аны аңламаган үсмер еш кына мошенник кебек җинаятьчеләр корбанына әверелә дә инде. Әгәр бала кисәк кенә үзгәрсә, үз эченә бикләнсә, тынгысызга әйләнсә, аның белән кара-каршы утырып сөйләшергә, эшнең нидә икәнен аңларга тырышырга кирәк. Кырын эшкә кушылган бала еш кына үзен нәкъ менә шулай тота башлый.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Бар да көтелгәнчә

Тыныч һәм оешкан төстә. Узган ялларда Россиядә Бердәм тавыш бирү көне узды. Республика халкы муниципаль берәмлек депутатларын өстәмә сайлауда катнашты. Аның нәтиҗәләрен Татарстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Андрей Кондратьев игълан итте.

– Өстәмә сайлауда тавыш бирү процессы тыныч, оешкан төстә, хокук бозуларсыз гына узды, – диде ул. – Беренче тапкыр тавыш бирүчеләрне игътибарсыз калдырмадык. Аларга бүләкләр дә бирелде. Яшь сайлаучылар белән элемтәләр ныгый.

Андрей Кондратьев әйтүенчә, әлеге сайлау – киләчәктә булачак зуррак сәяси кампанияләрнең репетициясе. Билгеле булганча, халыкның киләсе өч елда Россия Президентын, Татарстан Рәисен, Дәүләт Советы һәм Дәүләт Думасы депутатларын сайлауда катнашасы бар.

– Әле без башкарасы эш шундый күп. Зуррак сайлауларга әзерләнә башладык кына, – диде ул.

Сүз уңаеннан, узган сайлауда Татарстанда 71432 кеше сайлау хокукына ия, шуларның 29809ы яки 41,73 проценты тавыш бирүдә катнашкан. Казанда исә 34894 сайлаучының 6973е тавыш биргән (19,98 процент).

САЙЛАУ – САННАРДА

161 муниципаль депутат сайланды
122 – «Бердәм Россия»
7 – КПРФ
5 – «Новые люди»
2 – ЛДПР
23 – үзен үзе тәкъдим итүчеләр
Бер депутат мандатына – **3** кандидат
Участок сайлау комиссияләрендә **1,2 мең** кеше эшләде
650 күзәтүче
Тавыш бирү **36** районда барды

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Аеклык – заманга лаеклык

Камиллектән ерак җан иясе буларак, адәми зат «ычкынгаларга» ярата. Проблемаларны онытып торырга, чынбарлыктан качарга, хәтта акылдан да күпмедер читләшергә. Ничек итепме? Ысулы күптән билгеле: баш миендәге «рәхәтлек үзәге» дип аталган урынга төрле стимуляторлар белән тәэсир итеп. Андый стимуляторларның гомуми исеме – наркотиклар. Гәрчә ул сүзне ишетүгә гашиш, марихуана, әфьюн ишене күз алдына китерсәк тә, исемлек аның белән генә бетми. Шул ук аракы, виски, ром һәм башкалар да – наркотик. Рәсми, теләсә кайсы кибеттә сатыла торган иң күп кулланылышлы ул стимуляторлар – кешелекнең күпсанлы бәлаләренең берсе…

Һәр елны 11 сентябрьдә Россиядә Аеклык көне билгеләп үтелә. Дөресрәге, язуларынча, аны ике тапкыр билгелиләр. 3 октябрьдә әле тагын Халыкара аеклык көне дигән дата да бар. Билгеләвен билгелиләр, чаралар уздыралар, тик эчүчелек кенә кимергә ашыкмый. Һәм бер безнең илдә генә түгел. Ихтимал, спиртлы эчемлекләрдән Ходай бәндәсе беркайчан да котыла алмас. Әгәр дә алар бәйрәмнәрдә генә чик-чама белеп кулланылса, котылу хакында сүз куертмаганда да ярар иде. Бөтен хикмәт тә шул чаманы оныту сәбәпле килеп чыккан күпсанлы затсызлыклар – җимерелгән гаиләләр, кылынган төрледән-төрле җинаятьләр, авырулар, вакытсыз үлемнәр һәм башкалар аркасында. Чамадан чыгуны без эчкечелек, алкоголизм дип атыйбыз, һәм ул заман проблемалары арасында инде хәтсездән «лаеклы» урын алып тора. Аеклык көннәре кертелү дә юкка түгел: проблема хакында зурдан кубып уйланырга, гөнаһлы шөгыль белән көрәшергә чакыру ул.

Ил тарихында булсын, дөнья тарихында булсын, кайда гына нинди генә «коры закон»нар кертеп карамаганнар, тик канга сеңгән гадәттән биздерә генә алмаганнар. Киресенчә, андый чаралар еш кына кире нәтиҗә биргән – спиртлы эчемлекләрне үзлектән җитештерү, нәрсә яна – шуны эчү, наркотикларга мөрәҗәгать итүләргә кадәр тудырган. Шунысы да бар: дәүләтләр, бер яктан, эчкечелекнең начарлыгын аңлап, аның белән көрәшсә, икенче яктан, аракы җитештереп сату бюджетны тулыландыруның шәп ысулы икәнен дә аңлап эш иткән. Аракы ясауга дәүләт монополиясе булган патша Россиясендә, Советлар Союзында да нәкъ шундый хәл күзәтелгәнлеге мәгълүм.

Спиртлы эчемлек теге яки бу халыкның тарихында, культурасында, менталитетында электән булган, бар икән, тыюлар ярдәмендә киләчәктә аннан баш тарттыру мөмкин дә түгел. Биредә дин, дини культура да олы әһәмияткә ия. Диннәрнең исерткеч эчемлекләр куллануга мөнәсәбәте төрлечә. Ул күренешне күрмәмешкә салышканнар, «шайтан суы»н капкалауны хәтта хуплаганнар бар. Ислам гына яралганнан бирле – инде менә унөч гасыр буе исерткеч эчемлекләрне хәрамга чыгара, аны эчүне тыя. Бу урында тагын бер кат динебезнең бөеклеген искәртәсе килә: мөселман өммәтендәге халыкта, исламга чын күңелдән бирелгән кавемнәрдә без бүген сөйләгән проблема бөтенләй дә юк бит. Тик менә татар гына, диндарлык чагыштырмача сай булу сәбәпле, эчүчелек китергән бәлаләрдән әлегә азат түгел. Сай диндарлык, башка шундый гадәтләр кебек үк, яшерен-батырын түгел, башка культура тудырган уртак мохиттә яшәүгә дә бәйле. Ә бит башкача да булырга мөмкин иде.

Кайбер тарихчыларга ышанганда, Ибн Фадлан дәрәҗәсендәге Багдад илчеләре X гасырда Болгар дәүләтенә генә түгел, Киев Русенә дә килгән, ислам динен алырга аларга да тәкъдим иткән булган. Тик, риваятьләргә караганда, «Красное Солнышко» кушаматлы Киев кнэзе Владимир, имештер ки: «Веселие на Руси ест питие, без пития на Руси не быти», – дип аларны кире борган. Россияне бүген ислам дәүләте яисә төп дине ислам булган ил, рус кешесен мөселман итеп күз алдына китерү кыен.

Христиан дөньясы шактый зур, һәм аңа караган дәүләтләрнең барысында да диярлек бүген без сөйләгән гадәт, традицияләр саклана, дию дөрес кебек. Бары протестантларда гына исерткеч эчемлекләр куллануны катгый кысага куючы кануннар барлыгы мәгълүм. Ә башка дөньяви диннәр – кытайлыларның төп дине даосизм да, индуизм, буддизм, японнар тоткан сентоизм – берсе дә исерткеч эчемлекләрне тыймый. Ни өчен алар адәми затның шундый юл белән «ял итүенә», бушануына, алда әйтелгәнчә, «ычкынуына» каршы түгел соң?

Тыймау бәлки тагын да шул ук культурага, халыкның менталитетына барып тоташадыр – нәрсә һәм ничек эчәсең бит. Шул ук немецлар – сыра эчү буенча чемпионнар, француз шәрабсыз тора алмый. Тик бу хәл ул халыкларда исерекләр, газонда аунаганнар атлаган саен дигән сүз түгел. Кытайлар, японнар да эчә белеп эчәләрдерме, аларны алкоголизмда гаепләүчеләр күренми. Лаякыл исерү дигәндә, анысы, беренчедән, каты эчемлекләрне күп куллану гадәткә кергән тарафларда, икенчедән, эчү культурасы бөтенләй булмаган, ягъни тагын да шул чама белмәгәннәр арасында. Кайбер галимнәр теге яки бу халыкның эчү традицияләрен аның геномына да бәйли. Аракы ишене кирәгеннән артык үз иткәннәр булган кебек, организмы аны бөтенләй кабул итмәгән кавемнәр барлыгы да билгеле. Тик беренче очракта халык чаклы халыкның деградациягә берешүе, генофондның начараюы да сер түгел. Алкоголизмда нәселдәнлек факторы да еш күзәтелә – әтисе эчкәннең баласы да стаканга үрелүчән була…

Борынгы римлылар табынган күп аллалар арасында күңел ачу һәм шәраб алласы Вакх та булган. Бергә җыелып, вакханалия – шул аллага багышланган, кайчагында атналар буе барган бәйрәм гадәти күренеш саналган: ата – улны, ана кызны белмичә, тәгәрәп киткәнче эчкәннәр, кәеф-сафа корганнар, шәпләп «ычкынган»нар ромул уллары. Римны, варварлардан бигрәк, шул тотнаксыз типтерүләр, вакханалия юкка чыгармады микән? Кешелек, аерым кавемнәр бүген алар үткән юлны, алар ялгышын кабатламыймы?

ТАТАРСТАННЫҢ ҖИДЕ МОГҖИЗАСЫ



Сәяхәт

Якташыбыз, Казан дәүләт университетыннан «инженер-геолог-геофизик» белгечлеге алып чыккан Рәис МИҢНУЛЛИН шушы көннәрдә генә Россиядәге җиде могҗизаның берсе – Коми Республикасында цивилизациядән шактый еракта урнашкан Маньпупунер баганаларын күреп кайтты. Форсаттан файдаланып, без аның белән республикабыздагы могҗизалы урыннар турында да сөйләшеп алдык.

:: Рәис Мәрданович, сез, җиде могҗиза дип, күбрәк дөньядагы, Россиядәге күренешләр турында сөйлисез. Бу җәһәттән Татарстанда хәлләр ничегрәк?

– Миңа Җир шарындагы «Җиде могҗиза» дип аталган урыннарның бишесендә, ә Россия буенча җидесендә дә булырга туры килде. Бу күптәнге хыялым иде, акрын гына тормышка ашырып килəм. Җиде могҗиза Идел буе төбәкләрендә дә билгеләнгән. Аның өчесе – безнеке: Кремль, Болгар шәһәре һәм Зөя утравы. Татарстан исемлегендә дә, Казан исемлегендә дә нигездә корылмалар өстенлек алган. Минемчә, әле өйрәнелеп бетмәгән, риваятьләрдә сөйләнгән табигый байлыкларыбыз могҗиза сүзенә күбрәк туры килә. Монда, чыннан да, ниндидер ачылмаган серләр булырга тиеш бит инде. Ерак җирләрдәге могҗизаларны карап йөргәндә, үзем дә сизмәстән, һәр урынны Татарстан белән чагыштырырга яратам. Шул вакытларда табигатебезнең дә, тарихи һәйкәлләребезнең дә ни дәрәҗәдә үзенчәлекле икәнлегенә тагын бер кат инанам. Иң мөһиме, ерак барасы да юк бит. Барысы да янәшәдә генә. Мин тарафдарларым белән исемлек тә төзегән идем.

1. Лабач тавы
2. Печище геологик киселешләре
3. Чатыр Тау
4. Кыз тавы
5. Сүле аланы
6. Юрьев мәгарәсе
7. Сарман мәгарәсе

Лабач тавы Кама Тамагы районында, Идел белән Чулман тоташкан урында урнашкан. Казу эшләре барышында анда мамонт сөякләре табылган. Рәссам Илья Репин иң яхшы картиналарын (шул исәптән «Иделдә бурлаклар» картинасын да) шушы тау башында иҗат иткән. Монда Гражданнар сугышыннан калган окоплар хәзер дә бар. Ә Иделнең Югары Ослан районына кергән ярларында даны еракларга таралган, төрле төстәге Печище геологик киселешләре бар. Бу урыннарда Казан Кремленең стеналарын төзү өчен таш чыгарганнар. Әлеге киселешләрнең тасвирламасы хәтта Бөтендөнья Җир турындагы фән мәгълүматларына да кертелгән. Азнакай районында урнашкан Чатыр Тау исә матурлыгы, бөеклеге буенча Кырым тауларыннан бер дә калышмый. Апаста, Зөя буенда риваятьләрдә сөйләнгән Кыз тавы бар. Аның итәгендә җирле ГЭС төзелгән. Янәшәдә генә Тәтеш шәһәре янында Сүле (Долгая Поляна) дип аталган урын бик тарихи. Анда бик үзенчәлекле агачлар һәм төрле үсемлекләр үсә. Иделнең биек ярлары гадәти булмаган геологик комплекстан – тектоник җыерчыклардан гыйбарәт. Татарстан, тигезлектә урнашуына карамастан, мәгарәләр белән дә дан тота. Аларның берсе Кама Тамагы районында урнашкан. Бер километр озынлыктагы, карбонат токымнардан торган Юрьев мәгарәсе. Икенчесе – Сарманда. Анда XVII гасырда бакыр рудасы чыгарылган дип фаразлана. Мин санап киткән объектлар, әлбәттә инде, кызыклы, ниндидер әһәмияткә ия булган урыннарның бер өлеше генә. Күп еллар геологик разведка эшләрендә катнашучы кеше буларак, мөгаен, Татарстанда мин аяк басмаган урын калмагандыр. Шуңа да бу җиделекне могҗиза итеп сайлавым белән күпләр килешердер дип уйлыйм.

:: Минемчә, соңгы елларда халык күбрәк Юрьев мәгарәсе белән кызыксына. Моның сәбәпләре дә бар кебек. Ул башкалага да якынрак. Аннан килеп, рәсмиләштерелмәгән маршрут булса да, мәгарәне күрергә дип, туристлар шактый күп йөри, ял итәргә дә баралар. Кыскасы, телдән төшми торган як. Тик менә татарчага тәрҗемә итү мәсьәләсе генә кыенлык тудырды. Сүзлекләрдә, энциклопедияләрдә бу сүз тәрҗемә ителмәгән. Шуңа күрә интернетта кайберәүләр: «Нинди Юра ул?» – дип сорау да биргәннәр. Ә бит мәгарәнең барлыкка килүе тарихи юра чорына карый һәм исеме шуннан алынган. Бәлки аны Юра чоры мәгарәсе яки Юра мәгарәсе дип атау дөресрәктер?

– Монысы – дөнья гизгән кеше булсам да, минем өчен авыр мәсьәлә. Бу җәһәттән, чыннан да, филология галимнәре белән киңәшеп карарга булыр. Ә мәгарәгә килгәндә, ул, чыннан да, телдән төшми. Соңгы елларда бигрәк тә. Кыскача тарихы түбәндәгечә. Моннан 10 мең еллар элек тау токымнарының үзгәрүе нәтиҗәсендә бу урында мәгарәләр системасы барлыкка килгән. Төрле сәбәпләр белән аның берсе генә исән калган. Бүген бу мәгарәнең озынлыгы – 1005 метр, Урта Идел территориясендә озынлыгы буенча беренче урында тора. Күп вакытлар аның турында беркем дә белмәгән. Беренче тапкыр совет геологы Александр Ступишин 1957 елда тикшеренүләр үткәргән. Мәгарәнең озынлыгы 20 метр дигән нәтиҗә ясаган. Әмма, әйткәнебезчә, мәгарә тирәсендә энтузиастлар күп була. Төрле экспедицияләр аның бер чакрым чамасы икәнлеген ачыклый. Эш шунда: мәгарәнең «ишеге» һәрвакыт ачык. Шуңа күрә монда җәй буена спелеологлар да (тау куышларын, мәгарәләрне тикшерүче галимнәр), кызык күрергә килгән кешеләр дә өзелеп тормый. Әмма объект туристлар өчен җайлаштырылмаган, шуңа күрә һәр адымда куркыныч саклап торганлыгын онытырга ярамый. Дөрес, спелеологлар классификациясе буенча, бу мәгарә иң гадиләреннән санала. Димәк, анда әзерлексез кешеләр дә керә ала дигән сүз бу. Әмма үтәлергә тиешле кагыйдәләр бар.

:: Сарман мәгарәсендә хәлләр ничек?

– Әйткәнемчә, Сармандагы мәгарәләр табигый түгел. Элек заманда бу җирләрдә «Бакыр базы» дип аталган рудниклар булган, дип сөйлиләр. Шуның калдыклары. Әмма кайчан һәм кем бакыр чыгару белән шөгыльләнгән? Бу хакта тарих битләрендә мәгълүмат юк. Кайберәүләр аларны Петр I заманында швед әсирләре казыган дип әйтәләр, икенчеләре Болгар чорына караган шахталар дип атыйлар. Башка версияләр дә бар. Әлбәттә инде, бу очракта бәхәсләшүдән файда юк. Дөреслекне ачыклау өчен галимнәрнең җиң сызганып эшкә тотынуы кирәк. Тыштан караганда, бу мәгарә берни белән дә җәлеп итми кебек. Ун метрлар тирәсе тезләнеп керәсең. Ә эчтә басып торырга мөмкин. Бик салкын. Тагын шуны онытмаска кирәк: мәгарә лабиринт кебек, адашуыңны көт тә тор. Спелеологлар, әлбәттә инде, эчкә кергәндә карта алырга кушалар. Әмма бу кагыйдәне бар кешенең дә үтәмәве көн кебек ачык. Шуңа күрә игелекле кешеләр ишектән рудникка кадәр бау сузганнар. Шуңа тотынып йөрергә була. Мәгарәдән тыш монда йөз метр ераклыкта гына «Кара-каршы» дип аталган чишмә, янәшәдә генә буа бар. Беседкалар ясалган. Кыскасы, ял итәргә менә дигән урын.

Сарман мәгарәсе дә туристлар өчен җайлаштырылмаган. Моннан берничә ел элек аны, куркыныч дип, бикләп тә караганнар иде. Хәзер исә йозагы салдырылган, капкасы белән рәшәткәләре генә калган. Тиешле игътибар бирелсә, бу объект та Татарстан бренды булып хезмәт итә, акча да китерә алыр иде. Ни кызганыч, әлегә өмет белән яшәргә генә кала. Кыскасы, ничек кенә булмасын, республикабызда кызыксынырлык әйберләр бик күп. Шуңа да чит җирләргә киткәнче, башта Татарстанны ныклап өйрәнергә тәкъдим итәм. Бу, чыннан да, үзебезнең нинди байлыкка ия булуыбызны аңларга, чагыштырып карарга зур мөмкинлекләр бирә.

Әңгәмәдәш – Фәния ӘХМӘТҖАНОВА



vk.com

МӘГАРӘДӘ ҮТӘЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ КАГЫЙДӘЛӘР

✓Җир астына ялгызың гына төшәргә ярамый.
✓Төшкән вакытта бернинди алкогольле эчемлек кулланмаска, мәгарә эчендә тәмәке тартмаска.
✓Мәгарәдә ел әйләнә салкын, шуңа күрә үзең белән җылы кием алырга.



Рәсми хәбәр

Комплекслы кадастр эшләре башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын үткәрү турында хәбәрнамә

Түбәндәге территориядә: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районында урнашкан күчемсез милек объектларына карата (кадастр кварталы номеры 16:50:140404) 02.05.2023 ел, № №923000089-ОК дәүләт контракты нигезендә комплекслы кадастр эшләре башкарыла.

Кызыксынулы барлык затларга территорияләрнең карта-планнары проектларын әзерләүнең тәмамлануы, алар белән түбәндәге адреслар буенча танышырга мөмкин булуы турында хәбәр итәбез: барып – килештерү комиссиясенең эш урыны адресы: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 йорт (телефон: +7 843 223-20-00), яки

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының (https://mzio.tatarstan.ru);

Казан шәһәре Совет районы хакимияте (https://kzn.ru/meriya/administratsii-rayonov/sovetskiy);

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре комитеты (https://rosreestr.tatarstan.ru);

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе (https://rosreestr.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында.

Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышы 2023 елның 5 октябрендә (10 сәгать 00 минутта башлана) түбәндәге адрес буенча үткәрелә: Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Совет районы, Шуртыгин урамы, 1 йорт.

Чикләрнең урнашу урынын килештерүдә катнашу өчен, үзең белән шәхесне раслаучы документ, шулай ук тиешле җир кишәрлегенә хокукларны раслаучы документлар алып килергә кирәк.

Территориянең карта-планы проектындагы җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата нигезле каршы килүләрне килештерү комиссиясенә язмача 2023 елның 12 сентябреннән 2023 елның 5 октябренә кадәр һәм 2023 елның 5 октябреннән 2023 елның 9 ноябренә кадәр тапшырырга мөмкин.

Каршы килүләр «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» 24 июль, 2007 ел, № 221-ФЗ Федераль законның 42.10 статьясындагы 15 өлеше нигезендә рәсмиләштерелә. Бу җәһәттән тәфсилле мәгълүматлар сайтта (https://mzio.tatarstan.ru) урнаштырылган.

Мондый каршы килүләр булмаган очракта, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны килештерелгән булып санала.

ТАРХАНГА БӘХЕТ ЮРЫЙК

Илдар Мөхәммәтҗанов

Азнакай

Газ керсә, юл булса, авыл җанланачак. Азнакай районының Тархан авылы халкы әнә шулай дип өметләнә. Кайчандыр ташландык авылда кышын 83 яшьлек Венера Хисамиева үзе генә яшәгән. Хәзер инде яшьләр дә тартыла башлаган. Шәһәрдәгеләр өчен дә авыл – җылы кочак.

Дөресен генә әйткәндә, без бу авылга фермер Әмировларның болында йөргән ишәкләрен карарга дип сугылган идек. Кечкенә авылның урамын әйләнгәндә, «Ком чишмәсе» дигән язуга, зур самавырга күзебез төште. Заманында нефтьчеләр ясаган икән. Тирә-ягы – чәчкә. Монысы инде – авылның иң өлкән кешесе, әлеге дә баягы Венера апаның тырышлыгы. Сүнгән саланың ямьләнеп маташуы. Авырткан урыннары да юк түгел. Монысы инде табигый хәл.

Туу

Тархан авылы 1913 елда җирләрне хосусыйлаштыруга бәйле рәвештә барлыкка килә. Хосусый милекчеләр үз җирләренең бер урында туплануын тели. Биләмәләрнең төрле урында булуы уңайсызлыклар тудыра чөнки. Хафиз Хәлфин һәм аның иптәшләренең үтенече буенча Бөгелмә өязе җир төзү комиссиясе утырышында аларга җир бүлеп бирү мәсьәләсе карала. Шулай итеп, Илбәк авылыннан 24 хуҗалык яңа урынга төпләнә. Тархан авылында мәчет, зират өчен урын бүлеп бирелә. Указлы мулласы да була. Тик революциядән соң мәчетнең манарасын кисәләр. Ул бина авыл халкына мәктәп, медпункт, клуб, чеби фермасы буларак хезмәт итә. Беренче күмәк хуҗалык «Таң» дип атала. Сыер, тана, сарык фермалары оеша.

Тархан әкренләп кибетле, башлангыч мәктәпле, почталы, медпунктлы, тегермәнле авылга әйләнә. Бүген инде боларның берсе дә юк. Кирәк-яракны автокибет китерә.

Бүген авылда 80ләп җир кишәрлеге, шул исәптән искесен, яңасын санаганда 50ләп йорт бар. 11 йортта барлыгы 21 кеше теркәлгән. Җәй көне 50ләп кеше яши, кышны алты йортта гына чыгалар.

Сүнү

Тархан Сарман районының Җәлил бистәсенә якын урнашкан. Арасы – 5–6 чакрым. Шунлыктан авыл кешеләренең күбесе шунда күчеп киткән. Авылда калган картлар бакыйлыкка күчкән. Шулай итеп, Тархан бик кечерәя.

Венера Хисамиева 6–7 ел элек авылда үзе генә яшәгән. Мунчага дип кайткан күршеләрен, бик әйбәт иде, дип мактый. Хәзер ул – улы Айрат, килене Мөнирә тәрбиясендә. Кызы Люция – лаеклы ялда. Балалары, оныклары булышып тора.

Венера апа 14 яшеннән фермада эшләгән. Ул таркалгач, 18 яше тулганчы, бәхет эзләп, Ташкентка чыгып киткән. Әҗвәт белән кавышып, 55 ел гомер кичергәннәр. Картлык көннәрендә авылга күченеп кайткан алар. Тугыз ел элек ире үлеп киткән.

– Авылда үзегезгә генә күңелсез булмадымы? – дип сорагач, елап ук җибәрде.

– Шуңа күрә ишекне бикләдем дә 81 яшемдә Чаллыдагы Солтан дигән бер бабайга кияүгә киттем. Бер атна торуга авылны сагына башладым. Мәхәббәтнең нәрсә икәнен шушы яшьтә генә белдем. Чын-чынлап гашыйк булдым. Аны төрек солтаным дип йөртәм. Бик әйбәт үзе. Сагынганымны белә, бар өеңә кайтып кил, ди. Әле менә авылда яшим, – ди Венера апа. – Җәй көне авыл музейга әйләнә. Табигате искиткеч. Авылның бөтен кешесе кайта. Тыз да быз машиналар йөреп кенә тора. Шул чакта Тарханымның сулышын тоям.

Кабыну

1998 елга кадәр Тархан Мәсгут авыл җирлегенә караган. Шул елларда күп кенә кешеләр шушы авылдан җир алган. Җәй көне күбесе дача итеп тота. Бәрәңге, яшелчә утырта. Торуын тормасалар да, ташландык авылны җанландырып җибәргәннәр. «Газ кертәбез» дигән хәбәр дә элек чыгып китүчеләрне авылга якынайткан.

Раушания һәм Айрат Ситдыйковлар пенсиягә чыккач, Җәлилдән туган авылларына күченеп кайткан. Гаилә башлыгы – шушы авылныкы.

– Яз көне кошлар сайрый. Тыңлавы рәхәт. Кышын чаңгыда шуабыз. Балалар, оныклар кайта. Тик юллар гына үзәккә үтә. Яңгыр-буранда авылга бернинди ашыгыч ярдәм, янгын сүндерү машинасы да керә алмый. «Газ кертәчәкләр», – дип сөендерделәр. Түземсезлек белән көтәбез. Әлегә өйне электр ягып җылытырга туры килә. Кечкенә өйгә без айга 5 мең сум түлибез. Зуррак йортларның чыгымнары 15–20 мең сумга җитә, – ди Раушания ханым.

Әмировлар өчен Тархан бөтенләй ят. Монда кайтып, үзләренең мини фермасын ачып җибәргән. Ат, сыер гына түгел, ике ишәкләренә кадәр бар. Санын арттырмакчылар.

– Авылны да, эшне дә яратабыз. Әмма юл булмау кыенлыклар тудыра. Пычрак көнне авылдан чыгып булмый. Машина хәтта сөт җыярга да керә алмый. Шуңа күрә сөтне малларга эчертергә туры килә, – ди Миләүшә.

Әмировлар кайтуга бигрәк тә Венера апа сөенә, «Печәнне чабып, авылны чистартып торалар, тормыш ямьләнеп китте», – ди. Кемнең матурлыкта яшисе килмәсен ди?! Өстәвенә кеше белән аралашып, гәпләшеп, бербөтен булып.

Сәрия МИФТАХОВА

Мөнәсәбәт

Лилия ӘСАДУЛЛИНА, Илбәк авыл җирлеге башлыгы:
– Үзара салым программасы кергәч, юлларга бераз таш җәяргә тырыштык. Бөтенесенә дә булмады, әлбәттә. Бу эштә Җәлил бистәсенең нефть идарәсе булышты. «Юлларны карарга ярдәм итегез», – дип, ел да хат язып торабыз. Соңгы елларда авыл газлаштыру программасына кертелде, өйләргә газ килүен көтәбез.
Торбалар җир астыннан үтәчәк. Шуңа күрә юлларга тотынганчы, башта газ мәсьәләсен хәл итәсе иде. Авыл юллары бик тар. Кыш көне грейдер кертергә бик авыр. Кечкенә трактор белән чистарттырабыз. Газ кергәч, юлларга чират җитәр. Районның киләсе елларга үсеш планы бар. Шуңа кертү өчен, Тархан авылы юлларын яхшыртырга кирәк, дип гариза яздык. Авыл зураер дип өметләнәбез. Халкы өмәләрдә актив катнаша. Зиратын да, авылны да чистартып тора. Үзара салымны да күп җыялар.

Авыл җаны

Саклап калып булмый?

Бу – элеккеге авылларны сагынып язган язма түгел: вакыт тәгәрмәчен беркемнең дә туктата алганы юк әле. Бары тик бүгенге авылның ниндилеген аңларга тырышуым. Авыл кешесе нинди ул бүген? Ниләр уйлый ул? Нәрсәләр турында хыяллана? Үзем белгән (бәлки, беләм дип уйлаган гына) авыл кешеләре белән сөйләшүләрне язарга исәбем.

Авыл кешесенең портреты – авыл картинасының бер төсе ул. Кайберләре виртуаль авыл кешеләре булыр, алар интернет аша таныш миңа, «мең шәһәр»дән бер авылга өстенлек биргәннәр. Исем-фамилияләрен үзләре кирәк санаса гына үзгәртмәм. Бөтен кеше уй-фикерләре белән ачыктан-ачык бүлешергә әзер түгел бит.

Бүгенге язмамның авторы – Мансур абый (исемен үзгәрттем) лаеклы ялда. Авылда гына түгел, шәһәрдә дә аның кебек үзенчәлекле фәлсәфи-аналитик фикер йөрткән кешеләр сирәктер. «Мин һәм сез», «мин сезнең кебек түгел» дип «җиффәрергә» ярата. «Минем дәрәҗәмә менеп аңлый алсагыз, мин сезгә хаклыкны җиткерәм» диебрәк сөйләшә. Югары белемле, җитәкче урыннарда эшләгән кеше. Шактый еллар авылда яши инде. Авылда яшәвенең сәбәпләре аңлатып бетергесез күп ди: Җирнең табигатенә мәхәббәт, яшьли аңа яраклашып, яратып яшәү; яшелчәләр, гөлләр, чәчәкләр, чишмәләрне ярату һәм куллану; табигый тавышлар, җил, су, ис, төсләрнең өстенлек итүе; стратегик яктан мөһим объектларның ераклыгы, ягъни куркынычсызлык… (Мин шул рәвешле саныйм, чөнки Мансур абый шулай иркенләп, җәелеп сөйләргә ярата.) Шәһәрдә нинди шартлар бар, боларның барысы да авылда артыгы белән бар, дип саный ул.

Авылны ничек кенә яратса да, аны махсус программалар белән саклап калып булмаячак, ди Мансур абый. Элек авыл яшәү чыганагы иде, хәзер ментальность үзгәрә, авыллар шәһәр кешеләре өчен «жилой комплекс» булып кына калачаклар, ди. «Читтәге авыллар картайган буын белән бергә юкка чыгачак. Казан, Чаллы кебек зур шәһәрләр тирәсендә яңа поселоклар барлыкка киләчәк, алар җитештерү-техник прогресска, авыл хуҗалыгы кулланучыларына хезмәт күрсәтү урыны булачак». Элек колхоз-совхозлар вакытында продукция шунда яшәүчеләр өчен дә җитештерелә иде; мәктәп, клуб, бакча һ.б. төзелә иде, акча җыеп, ял итәләр иде, ягъни бу җир андагы кешенең яшәү чыганагы иде, хәзер болар бар да бетәчәк, ди.

Мансур абый фикеренчә, хәзер күчеш чоры бара. Авыл эре олигархлар, эре агрохолдинглар өчен хезмәт күрсәтүнең бер буыны гына булып калачак. Әле үзләре өчен эшләгән ИП, ОООлар, КФХ, ЛПХлар, кооперативлар бар. Тора-бара бары эре агрокомбинатлар, агрохолдинглар гына калачак, чөнки кечкенә хуҗалыклар алар белән көндәшлек итә алмый. Инде хәзер үк егерме-утыз гектар җире булган ЛПХлар җирләрен азайта башлады, ди ул. Пай җирләрен сатып алып, биш-алты йөз гектар җирләре булган хуҗалар да бар; алар да тора-бара үзара кооперациясез яши алмаячак.

Авыл кешеләрен, вахталар килеп, төрле җиргә эшкә алып китәчәк: колбаса заводларына, элеватор, КАМАЗларга… Анда шәһәр кешесе дә, авыл кешесе дә бергә эшләячәк. Авыл фатир шикелле генә, яшәү урыны гына булып калачак.

«Авылны саклау» дигән сүзгә карата да үз фикере Мансур абыйның. Ул бюджет акчасын үзләштерү өчен бер мөмкинлек кенә, ди. Олигархларның (алар Мәскәүдә дә, Грециядә дә яшәргә мөмкин), эре холдингларның авылны элеккечә сакларга дигән бер генә максаты да юк, ди.

«Татарлыкны авылда саклап булмый, татарлыкны авылда картайтып, үтереп кенә була. Татарлыкны шәһәрдә дә саклап булмый. Аны иман белән генә саклап була. Россия Хөкүмәте ислам диненә хәзерге көндә үсәргә зур мөмкинлек бирде. Ислам аша гына телне саклап була. Ислам иманны саклый, иманлы кеше телен саклый. Безнең телгә ихтыяҗ бетте хәзер. Ул түшкә ясалма беркетеп куелган орден кебек кенә».

«Кешенең баш миенә контроль авылда да, шәһәрдә дә система аша, эш урыннары аша башкарыла…»

Менә шундый кызыклы кеше Мансур абый. Прогнозы оптимистик түгел, әлбәттә. Мөгаен, икенче юлы, «Аллаһка шөкер» дип, шөкрана итеп яшәүче берәр кеше турында язармын. Ачы хакыйкатькә караганда, баллы кәнфит тәмлерәк бит. Күп ашасаң, тешне черетә, шунысы гына начар.

Лилия ФӘТТАХОВА

Сораштыру

Йодрык кадәрлеме?

Бәрәңге – бәхет эше. Җәй коры булуга карамастан, берәүләр, бәрәңге бик уңды, дип куанса, икенчеләрнеке хәтта тавык йомыркасыннан да кечерәк. Махсус үстерсәң дә, шуның кадәр кечкенә булмас. «Андыен ресторанда гына ашаталар», – диючеләр дә юк түгел. Көлсәң көл, еласаң ела. Без авыл халкының кәефен белештек.

Роза һәм Нурулла ГАЙФЕТДИНОВлар, Кукмара районының Тәмле Чишмә авылында кышны чыгучы бердәнбер гаилә:
– Быел бәрәңге бик вак. Болай начар булганы юк иде әле. Югыйсә су да сибеп карадык. Беренчедән, кырау төште. Икенчедән, яңгыр яумады. Сәбәбе шул. Кырау суккан урыннарга июнь ахырында бәрәңгене кабат утырттык. Әлегә кипкән төпләрен генә казыдык. Аннан ун чиләкләп чыкты. Яшел сабакларны сентябрь ахырына калдырдык. Бәлкем, алары яхшы булыр.

Морис НӘГЫЙМОВ, бакчачы (Биектау районы Дөбьяз авылы):
– Бәрәңге уңды. Уңышы узган елгы белән бер чама. Ике-өч төптән – берәр чиләк. Без бит су сибәбез. Тик моның рәтен белергә кирәк. Су сибүгә үк төбен йомшартып куям. Гомумән, бәрәңге төбен чәчәккә бөреләнгәч кенә өя башлыйм. Бу бәрәңгенең эрелегенә тәэсир итә. Күп кеше алдан ашыгып өя. Ашыгырга кирәкми.

Василий ИВАНОВ, Кукмара блогеры:
– Быел бәрәңге уңышы әйбәт. 11 сутый утырткан идек. Ничә капчык чыкканын санамадык. Су сипмәдек. Узган ел бәрәңгене каты корт (проволочник) күп ашаган иде. Шунлыктан шактые зарарланды. Быел тиресне әллә күбрәк керткәнгәме, бик азында гына күренә. Үзебез ашыйбыз, малларга ашатабыз.

Гөлзада апа СӘЛАХОВА (Арча):
– Быел бәрәңгебез бик тә шәп булды. Моның кадәр күргән юк иде әле. Йодрык зурлыгы гына түгел, бала башы кадәр. «Ред Скарлет» сорты бу. Беренче тапкыр гына утырту әле. «Беллароза» дигәне дә әйбәт. Анысы бик чыдам, череми. Дүрт чиләктән 55 чиләк эре бәрәңге алдык.

ЗООПАРККА БАРАСЫ ДА ЮК

Әлмәт

Үзем күрдем

Әлмәт районының Сөләй авылында яшәүче Радик Гыйбадуллин авылдашларына аю, ишәк, тагын әллә нинди ят кош-кортлар алып кайтып күрсәткән. Боларны үз хуҗалыгында да асрап караган ул. Хәзерге вакытта 17 баш ат, 15 сыер һәм башка мөгезле эре терлекләр тота. Тиздән гаилә фермасында декоратив кошларга да урын табылачак.

Зур колаклы «ат», баллы ашаучы аю

Радик Гыйбадуллин туып үскән нигезендә гаиләсе һәм 76 яшьлек әнисе Ләйсәнә белән яши. Хатыны Айгөл белән ике бала тәрбияли. Уллары күптән түгел өйләнеп, үз тормышын корган. Әлмәттә мал табибы булып эшли икән. Кызлары 9 нчы сыйныфта укый. Гаилә башлыгы белгечлеге буенча – юрист. Әмма мал, кош-кортлар кечкенәдән күңеленә якын булгач, терлекчелек юлын сайлаган. Маллар аңа яшәү көче бирә икән. Үзен чын җир кешесе дип саный ул. Биш ел элек гаилә фермасы булдырганнар. Сөт һәм итчелек белән шөгыльләнәләр. Үз җирләре дә бар.

Шәһәрдә бер көн дә торырга яратмый Радик. «Авылда яшәү – яшәү ул, ә шәһәрдә исә җан асрау гына», – ди 46 яшьлек ир. Үзенчәлекле терлекләр асрап үз тормышын гына ямьләндереп калмый, башкаларга да шатлык өләшә. 7–8 ел элек Казахстанның мал базарыннан бер пар ишәк алып кайткан. Шуларга балаларны утыртып авыл әйләндергән. И, сөенгәннәр инде сабыйлар. Мәш килеп фотога төшкәннәр. «Нинди зур колаклы ат бу?» – дип сораучылары да булган. Аңа кадәр пониларга да утыртып йөрткәләгән. Ишәк кире хайван булса да, хуҗасына тугры икән. Тагын бер үзенчәлекләре бар: иртәнге якта озаклап бик каты итеп кычкыралар. Төп ризыклары – солы, арпа, печән кишер, чөгендер. Тора-бара ишәкләрнең саны бишкә җиткән. Ә аннары аларны гаилә башлыгы Сарман, Азнакай, Әлмәттә яшәүче танышларына бүләк иткән.

Илдар Мөхәммәтҗанов

7–8 ел элек Казахстанның мал базарыннан бер пар ишәк алып кайткан. Ә аннары аларны танышларына бүләк иткән.

Зоопарктан алып кайткан аю – үзе бер тансык. Әлбәттә, аны бардың да алдың түгел. Закон буенча паспорт белән рәсмиләштерергә кирәк. 1,5 яшьлек аю баласы бу. 1,7 метр буйлы җәнлек кулга тиз ияләшкән, берәүгә дә тимәгән. Кешеләр белән уйнарга яраткан. Махсус читлектә яшәгән. Әмма ерткычка ышаныч юк дип, бер елдан соң хуҗасы аны кире илткән.

– Ерткыч булса да, чи ит ашамый иде ул. Ризыкның пешкәнен генә бирә идек. Үзебез ашаган ашны ашаттык. Талымламады. Баллыны бигрәк тә ярата иде, – дип искә алды Радик йонлачын.

Атлар яратучы нәсел

Гыйбадуллиннар ат асрау белән күп еллардан бирле шөгыльләнә. Бабалары нәселле атлар тоткан. Оныгы исә бу эшне дәвам итә. Заманасында баш саны 200гә җиткән. Радик Россия буйлап ат чабышларында да катнашкан. Хәзер инде сату өчен асрый. Без килгәндә маллар көтүдә иде. Көтүне исә Саратовтан килгән Олег көтә. Сигез ел эчендә гаиләнең үз кешесенә әйләнгән ул. Шуларда яши. Авылдан бер дә китәсе килми икән.

Табышы турында да кызыксындык. Терлекләрне суеп саталар. Алучыны читтән эзләп йөрисе дә юк. Авыл халкы ел дәвамында ит сорап тора. Килосы – 480 сум. Сөтне Әлмәткә барып саталар.

Моңа кадәр төрле токымлы кош-кортлар да тоткан Радик. Фазан, тәвә һәм башка ят кошларны төрле күргәзмәләрдән алып кайткан. Сөләйлеләр генә түгел, башкалар да махсус карарга килгән. Менә шулай Гыйбадуллиннар хуҗалыгы кайчак зоопаркка әйләнә дә куя. Акча түлисе юк бит, бушка күрсәтәләр. Радик яңа сарай салып, тәвә кошлары, кыр казлары, аккошлар һәм башкасын алып кайтмакчы. Кош-кортларны бик ярата икән. «Матурлык бит ул! Үзе бер соклану», – ди. Үзләренең кушаматлары да Чыпчык икән.

Сәрия ХАФИЗОВА

АЭСК

«ООО «Альтернативная энергосбытовая компания» уведомляет, что в соответствии с постановлением Правительства Российской Федерации № 24 от 21.01.2004 «Об утверждении стандартов раскрытия информации субъектами оптового и розничных рынков электрической энергии» на официальном сайте Компании http://tataesk.ru/ размещена в полном объеме информация об объеме фактического полезного отпуска электроэнергии и мощности по тарифным группам в разрезе территориальных сетевых организаций по уровням напряжения ООО «Альтернативная энергосбытовая компания».

Соклану

Туган ягы кирәк кешегә

Мичтә пешкән коймак, үләнле чәй. Казан халкын һәм якташларын балтачлылар әнә шулай каршы алды. Ул көнне Ленин исемендәге мәдәният йорты каршы Сабантуй мәйданына әйләнгән иде.

Балтачлылар буш кул белән килмәгәннәр. Үз продукцияләрен саттылар. Алучылар хәтта чиратка тезелгән иде. Бәяләре дә арзан, сыйфаты да яхшы, әле җитмәсә, һәркайсында туган як җылысы бит аларның.

Урманнан ук башланган очрашулар мәдәният йорты эчендә дә дәвам итте. Бередә кул эше осталары үз эшләрен күрсәтте. Алар арасында милли бизәнү әйберләре ясаучы Гүзәл Габидуллина, бөтен районның җыр-бию коллективларына костюмнар, куллмәкләр тегүче Гөлнара Эркәева, кунакларны район тарихы белән таныштыручы Фирая Зыятдинова, республикакүләм «Без тарихта эзлебез» шәҗәрә бәйгесендә җиңгән Гөлсем һәм Муллануp Миннебаевлар, милли ашлар әзерләүче Альбина Фәтхиева, китапханәчеләр, комган ясаучылар, гөслəчеләр дә бар иде.

Исегезгә төшерәбез: республикада «Татарстанның мәдәни башкаласы» дип аталган бәйге дәвам итә. Ул Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы уңаенан удырыла. Бәйге 31 марттан 24 ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк. Җиңгән район 3 миллион сумлык сертификатка ия булачак. Әлеге акча алга таба мәдәни проектларны үстерү өчен тотылачак.

Мондый чаралардан авыл кешесенә тагын бер кат сокланып кайтасың. Аларның уңган-булганлыгына, талантына шаккатасың. Һәр район үзенчәлекле. Үзенең милли ризыгы, гореф-гадәте, йолалары белән аерыла алар. Мөгаен, Балтач районының Түбән Сосна авылында яшәүче Закировлар кебек оста итеп берәү дә чабата бизени башкармыйдыр. Тамашачы алкышларга күмде үзләрен. Арбор авылында яшәүче Әкълимә Хәбибуллинадагы моң бөтен Авиатөзелеш районына таралгандыр кебек. Менә кайда ул талант! Монда, җырлыйм дип, аранжировка да яздырасы түгел, фонограмма да кирәкми. Моңың бар икән, ул тышка чыкмый калмый. Әнә Әкълимә апаныкы чишмә сыедай челтери бит әле! Аның үз-үзен тотышы, матур киемнәре дә таң калдырды. Гомере буе колхозда эшләгән икән ул. Авылдашлары әле аның бик кешелекле, ярдәмчел икәнен дә әйтә.

Удмурт егет-кызлары да, керәшеннәр дә, марилар да бик матур чыгыш ясады. Бию бик күп булды. Егет-кызлар, абый-апалар үз хәрәкәтләре аша тормышларының бар асылын ачты да салды кебек. Сүзләр дә кирәкми. Матур итеп яшәүләре, тырыш хезмәтләре чагыла иде аларда.

Тамашачы «Ядкарь» ансамбле чыгышын да яратты. Аларны инде бөтен республикада беләләр. Күп кенә бәйрәмнәрдә чыгыш ясап йөрүче, Марат Габделхаков җитәкчелегендәге Арбор авылы үзешчәннәре алар. Субаш авылыннан килгән гөсләчеләр чыгышы вакытында залда чебен очкан тавыш та юк иде. Гөсләне түгел, күңел кылларын чиерттә кызлар. Кыскасы, эштән соң килгән һәр кеше бередә ял итте.

Балтач районы элек-электән башкаларга үрнәк булып торган. Якташларын сәламләгән район башлыгы Рамил Нотфуллин да, без бик күп бәйгеләрдә алдынгы урыннар яулыйбыз, ди.

– Мондый чара барлык милләтнең гореф-гадәтләре белән таныштыру һәм тәҗрибә уртаклашу өчен кирәк. Безнең бурыч – районда яшәүче һәр милләтнең мирасын саклау. Ел саен үзара салым акчасына 60 миллион сумлык эшләр башкарыла. Районда яшәүчеләр өчен уңай шартлар тудырырга тырышабыз. Биргә килгән һәр кешегә рәхмәтемне җиткерәм, – диде башлык.

Хәзер генә түгел, элек-электән алдынгы булдылар, ди Татарстанның Дәүләт Советы депутаты Камил Нотаев та.

– Куйбышев районында башлык булып эшләгән чак. 1980 нче еллар башында безне Балтачка җибәрделәр. Эшкә өйрәнергә. Ике мәртәбә килеп киттек. Татарстанда беренче булып, колхозда ике сменалы эш оештырган иде алар. Борчактан сенаж салуызны күреп кайттык. Андагы борчактан консервланган банкадагы кебек иде. Сезнең халык районы белән бик горурланып яшәргә тиеш. Республикага бик зур шәхесләр биргән төбәк бит сез, – диде ул.

Татарстанның мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов та Балтачны «зур тарихлы һәм бай мәдәниятле як» дип атады.

– Сездә тормышны сөйгән, эш яраткан халык яши. Елдан-ел район яңара. Әлләминди зур эшләр башкарып ятасыз. Сездә иң борынгы гореф-гадәтләр, милли ашлар сакланып калган. Бу бәйгедә чыгыш ясау өчен күп көч куела. Моны оештырып чыгар өчен бердәмлек кирәк. Барыгызга да зур рәхмәт, – диде ул.

Концерт тәмамлангач та якташларын сагынып килгән Казан халкы өенә кайтырга ашыкмады. Якташлары булмаса да, бу чарадан мин дә бик сөенеп, рухи байлык алып кайттым.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ФЕСТИВАЛЬ САБАГЫ

В.Янчишин

«Иң яхшы тулы метражлы нәфис фильм» номинациясендә икенче ел рәттән Иран фильмы җиңде һәм төп призны алды. «Без предварительной договоренности» кинокартинасының режиссеры – Бехруз Шоайби.

«Татарстан киносын үстерүе белән кадерле». Һәр мөселман кинофестивале саен әйтелә торган сүзләр бу. Премьералар күрсәтелде, милли кино индустриясе турында фикер алышынды, фильмнар бәяләнде һәм җиңүчеләр ачыкланды. XIX Казан халыкара мөселман киносы фестивале ниләр белән истә калды, нәтиҗәләр нинди? Куелган максатларга ирешә алдыларм ы?

Фестивальнең оештыру комитеты рәисе, Татарстан Премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразыев ябылу тантанасында һәркемгә уртак хезмәт өчен зур рәхмәтен җиткерде.

– Казанда халыкара мөселман киносы кинофестивален уздыру Россия һәм Ислам дөньясы илләре арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерүгә зур өлеш кертә. XIX фестиваль белән без мөселман дөньясы һәм Россия мөнәсәбәтләре нигезенә тагын бер кирпеч салдык, – диде Васил Шәйхразыев. – Инде егерменче кинофестивальгә дә планнар төзи башладык. Жюри әгъзалары фестивальнең елдан-ел уңышлырак булсын өчен нәрсәләргә игътибар итәргә кирәклеген киңәш итте.

Мөселман киносы фестивале безгә Татарстан киносын үстерүе белән кадерле һәм әһәмиятле. Моны Татарстан мәдәният министры Ирада Әюпова фикере.

– Без еш кына фестивальнең ни өчен кирәклеге турында уйланабыз. Бу режиссерларның яки төрләрнең мактану ярминкәсе яки аралашу өчен мәйданчык кына түгел. Фестиваль – беренче чиратта бу җирлектә туган кино өчен мәктәп. Якын елларда Татарстан милли киносын үсеш кәтә дип чын күңелдән ышанам. Моның өчен тәҗрибә, белем тупланган инде. XIX фестиваль ул – зур тәҗрибә, – дип сөйләде министр ябылу тантанасында.

Россия кинематографистлары берлегенең Татарстан булеге рәисе Илдар Ягъфәров та татар киносы киләчәгенә зур өметләр баглый:

– Татарстан киносы юктан гына барлыкка килмәде. Аның үткәне, бүгенгесе һәм зур киләчәге бар. Бездә яшьләр бик күп. Яңа дулкын, киләчәккә зур өмет бар, – диде ул журналистларга.

Быелгы фестивальдә 21 илдән 52 кинокартина тәкъдим ителде. Биш көн дәвамында кинотеатрларда 100ләп фильм күрсәтелде. Иң куандырганы: соңгы берничә елдан аермалы буларак, быел үзебездә төшерелгән фильмнар тагын да күбрәк булды. Төп конкурстан тыш, фестивальнең «Милли конкурс» программасында 12 фильм тәкъдим ителде.

Фестивальдә тәкъдим ителгән фильмнарны, гадәттәгечә, төрле илләрдән танылган кино тәнкыйтьчеләре һәм режиссерлар бәяләде. Алар арасында Согуд Гәрәбстаны, Төркия, Кытай, Грузия, Азәрбайҗан, Тунис белгечләре бар иде. Жюри рәисе – танылган Сенегал режиссеры Мусса Туре. Ул фестивальне оештыру дәрәҗәсен һәм фильмнарны югары бәяләде.

– Татар фильмнарында мин азмы-күпме үземне таптым. Безнең мәдәниятләрдә, чыннан да, уртаклыклар бик күп. Җиңүче фильмга килгәндә, ул безне сәяхәткә алып кереп китте. Мәдәниятне, кешелеклелекне, бала мәхәббәтен һәм сүзләрнең күпмәгънәлелеген аңларга ярдәм итте, – диде жюри рәисе.

Кинофорумга нәтиҗә ясап, Мусса Туре Татарстанда фильм төшерү турында уйлавын да әйтте:

– Бу эшне башкара алырлык кешеләрне эзлим. Бәлки, бу ак һәм кара ислам арасындагы охшашлык турында фильм булыр, – диде Сенегал режиссеры.

Мөселман киносы фестивале кино «йолдыз»ларыннан башка узмый. Быел да танылган шәхесләр күп килде. Төп кунак исә танылган серб кинорежиссеры Әмир Кустурица булды.

Казан мөселман киносы фестивален үнтугызынчысы узды. Милли кино үсешенә дәрт һәм көч өстәде. Яңа фильмнар бар икән, хәрәкәт, үсеш тә бар дигән сүз бит. Хәзер инде зур түземсезлек белән егерменче фестивальне көтәбез.

Ләйсән САФИНА

ИЛФАР КӘРИМОВ:

«БҮГЕН РАДИОНЫ 15 МИНУТТАН АРТЫК ТЫҢЛАМЫЙЛАР»

Бүгенге радиотыңлаучыга нәрсә кирәк? Замананың тизлеге арту татар радиоларына ничек йогынты ясый? Җырларны сәнгать советы аша уздыручы «Болгар радиосы»нда элеккеге көйләр яңгырармы? Бу һәм башка сорауларны радионың башкарма директоры Илфар КӘРИМОВка бирдек.

:: «Болгар радиосы» яңа сезонда тыңлаучыларына нинди яңалыклар әзерләде?

– Элек-электән «Болгар радиосы»н «алтын хитлар» радиосы дип атыйлар иде. Чөнки безнең дулкыннарда ретро җырлар бик күп яңгырады. Бу сезонда исә, аудиториябне яшәртү максатыннан, яңа җырларга йөз тотарга булдык. Моңарчы безне күбесенчә 45–50 яшьлекләр тыңлаган булса, хәзер 30–35 яшьлек тыңлаучыларны җәлеп итәргә тырышабыз. Билгеле, бу радио фондындагы җәүһәрләр бөтенләй онытылачак дигән сүз түгел. Алар өчен махсус сәхифәләр бар.

Аннан соң, замана таләпләренә туры китереп, тапшырулырның вакытын да кыскартырга карар кылдык. Бүген кайда да динамика кирәк бит. Шуңа күрә элек эш көннәрендә 10–15 минут барган кайбер тапшырулар 2–3 минутка калды. Алар төрле темаларга багышланган сәхифәләр рәвешендә тәкъдим ителәчәк. Билгеле, 2 минутлык тапшыру әзерләү 10–15 минутлык тапшыру әзерләүгә караганда күпкә авыррак. Ләкин бездә үз эшенең осталары эшли – башкарып чыгарасыларына шигем юк. Ял көннәрендә исә аерым программабыз бар. Андагы тапшыруларның вакыты үзгәрми.

:: Яңа җырларга өстенлек биреләчәк, дидегез. «Алтын хитлар»га ияләшкән тыңлаучыларыгыз тәнкыйтьләр дип курыкмыйсызмы?

– Тәнкыйть булмыйча калмас иде. Булырга тиеш тә ул. Һәр тыңлаучының – үз радиосы, һәр радионың үз аудиториясе булырга тиеш дигән фикердә мин. Әйтик, ретро җырлар яратучылар өчен «Тәртип» радиосы бар. Яшьрәкләр «Татар радиосы»н тыңлый. Әйткәнемчә, бездә дә ретро җырлар булачак ул. Ләкин алар ны тансык, «тәмле» генә итеп бирергә телибез. Кеше радионы барыбер яңалык ишетер өчен кабыза. Дөньядагы яңалыкларны гына түгел, яңа җырлар да тыңларга тели ул.

:: Яңа сезонда яңа тавышлар ишетеләчәкме?

– Алып баручылар составында үзгәрешләр юк. Әмма тиздән яңа тавышларга кастинг уздырырга ниятлибез. Радиода эшләргә теләге, идеяләре булган яшьләрне эзлибез.

:: Хәзерге вакытта радиотыңлаучылар иң яратып тыңлый торган тапшыру кайсы?

– Кызганыч, бездә андый статистика алып бару бик кыен. Шуңа да без тыңлаучыларның фикерләренә колак салабыз. Гади генә мисал: радио аша азан ярты минутка гына соңрак яңгырас, шунда ук шалтырата башлыйлар. Гомумән, дини тапшырулар белән кызыксынучылар шактый. Аннан соң, җәй көне «Иртәнге чәй» тапшыруы ялга китеп торган иде, аны да бик юксындылар.

:: Бүгенге радиотыңлаучы ни дәрәҗәдә үзгәрде? Аңа нәрсә кирәк?

– Радиотыңлаучылар замана белән бергә үзгәрде. Замана тизлеген арттырган саен, тыңлаучы да тизлек, динамика кирәк. Бүген радионы 15 минуттан артык тыңламыйлар. Тиз мәгълүмат кирәк, тыңлаучы аны анализлап торырга әзер түгел. Бигрәк тә радионы фон өчен кабызучылар. Радиотыңлаучыга кыска мәгълүмат бирү һәм аның артыннан яраткан җырын кую кирәк. Без дә шуны истә тотып эшлибез.

:: Белүемчә, сездә әле дә сәнгать советы эшли. Җырлар сайлау ни рәвешле башкарыла һәм аларны кемнәр сайлый?

– Хәзер җырлар да, җырчылар да бик күп. Безгә дә атна саен 15–20ләп яңа җыр китерәләр. Билгеле, һәркайсын үткәрә алмыйбыз. Мәгънәсе дә, көе дә туры килми торганнары бар. Һәр эшне сыйфатлы итеп эшлисе, радиотыңлаучыларга ошый торган җырлар сайлыйсы килә. Шуңа да бездә атна саен сәнгать советы утырышы уза, эфирга да алар аша үткән җырлар гына эләгә. Җырларны кемнәр сайлый, дигәндә, ул советның составы үзгәреп тора. Аңа радиода эшләүчеләр дә, шагыйрьләр дә керә. Ләкин тәгаен кемнәр булуын игълан итмибез. Бу шул исәптән читтән басым булмасын өчен дә кирәк.

:: «Болгар радиосы» уздыра торган Милли музыкаль премия турында да сорыйсы килә. Быел нинди яңалыклар әзерлисез?

– Алла боерса, аны 9 декабрьгә планлаштырабыз. 30га якын җыр һәм җырчы бүләкләнер дип көтелә. Яңалыкларга килгәндә, сәхнә бизәлешендә үзгәрешләр булачак. Режиссеры да башка булыр дип көтелә. Билгеле, бу әвтәләккә дә йогынты ясамый калмас. Кыскасы, һәрвакыттагыча сыйфатлы, кызыклы бәйрәм әзерлибез.

Әңгәмәдәш – Лилия ГЫЙМАЗОВА

ИЛФАР КӘРИМОВ ФИКЕРЕНЧӘ, РАДИО ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ТӨП 3 ПРОБЛЕМА

1 Кадрлар җитмәү. Яшьләр арасында татар телендә иркен фикер йөртә торган, гомумән, фикерләүгә сәләтле булган, кызыксынучан яшьләр табу шактый авыр.

2 Радиотыңлаучыларның игътибарын җырлар, тапшырулар белән җәлеп итү кыен. Үзеңә кирәкле җырны, тапшыруны теләсә кайсы вакытта табып алып тыңларга мөмкин.

3 Техник мөмкинлекләр. Радио дулкыннарын һәр районга җиткереп тору өчен зур техник көч сарыф ителә. Билгеле, техник проблемалар да булмыйча калмый. Әмма без аларны тиз арада хәл итәргә тырышабыз.

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Кацо булдыра!

Мин «Салават» җыр театрында эшләгәндә, Салаватның жако токымлы Кацо исемле попугае бар иде. Ул төрле сүзләр кабатлый һәм төрле авазлар чыгара. «Козел» дигән сүзне әйтергә ярата, телефон шалтыраган тавышны чыгара. Ул вакыт – Салаватның Чаллыдан Казанга күченеп йөргән чоры. Салаватның студиясе – Чаллыда, мин инде Казанныкы булганга шул студиядә яши идем. Анда тәртип саклап торучы, кирәк булса, ашарга пешерүче Мәдинә исемле ханым бар иде. Әлеге попугай күпмедер вакыт Мәдинәләрдә торган икән. Шунлыктан Кацо аның исемен өч төрле итеп әйтә иде. Беренчесе – Мәдинә, икенчесе – Мадин, өченчесе – Мадина.

Әлеге попугай күпчелек вакыт шушы студиядә яши иде. Кергән һәр кеше аның белән сөйләшергә, теләсә нинди ризык биреп сыйларга тырыша. Шунлыктан аның читлегенә: «Меня не кормить всякой ерундой!» – дигән язу ябыштырылган иде.

Көннәрдән беркөнне Кацоны Казанга алып киттеләр, ул көннәрдә Салават барысына да ял бирде, минем барыр җирем юк, берүзем шул студиядә ятам. Тәрәзә янында басып тора идем, Салават белән Альфрид Якшимбетов килеп туктадылар. Тиз генә бер бит кәгазь алдым да попугай урынына барып утырдым. Менә ишек ачылды – керделәр, мин исә Кацо чыгара торган авазлар чыгара башладым. Тегеләр сак кына атлап бүлмәгә керделәр. Салават минем язуны укыды да «егылды»… Ә мин анда болай дип язган идем: «Меня кормить! Но не всякой ерундой!» Көлеп туйгач, Салават болай ди: «Килеп керсәм, Кацо тавышы! Аның Казанда икәнлеген белсәм дә, күңелгә ниндидер шик керде, авазлары шул ук бит!»

Салават шаяртуларны бик ярата. Сәхнәдә дә: «Миннән теләсәгез ничек көлегез, тик сыйфатлы һәм тамашачыга кызык булсын!» – ди торган иде. Әгәр кеше, бигрәк тә сәнгатьтә үзеннән көлә белми икән, ул бәхетсез! Ә Салаватта үз-үзеннән көлү бик көчле, аның кешеләргә ошавының бер сәбәбе шушыдыр. Әгәр үз-үзеңә гашыйк булып, купшы күркә кебек йөрисең икән, синең бәяң – «өч тиен»! Бик күбәүләр Салаватка бары җырчы буларак, язмышның иркә баласы итеп көнләшеп карыйлар. Ә Салават – тулы бер дәвер, ул укылмаган китап кебек! Гомумән артист тормышы читтән карап торганда гына җиңел тоела, ә ул – авыр хезмәт! Солдатта булмаган кешегә солдат тормышын аңлата алмаган кебек, артист тормышының нечкәлекләрен сөйләп кенә аңлатып булмый! Хәер, нигә «артист күлмәге»н үзеңә җайлаштырырга тырышырга, кирәк нәрсә түгел ул, бөтен кеше дә популяр җырчы булып бетә алмый. Артистлар – тормышны билгеле бер дәрәҗәдә матурлар, күңелле итәр өчен туган кешеләр. Шулардан ләззәт алыгыз!

***

Әле кайчан гына «Мөкәрәмә» такмаклары, «Урсал тау» белән татар дөньясына кергән Салават инде үзенең 35 нче сезонын үткәрде. Камал театры дисәң, Салаватны күзаллыйсың, Салават дисәң, Камал театры күзаллана! Август аенда халык театрга агылыпмы-агыла. Аннан инде Россия буйлап сәяхәт башлана. Тамашачы Салаватны һәм аның театрындагы сәнгать әһелләрен һәркайда түземсезлек белән көтеп ала. Салават чорында яшәвебез белән без бик бәхетле.

Илсур МОРТАЗА,
Татарстанның атказанган артисты

pixabay.com

Илдар Мөхәммәтҗанов

ҺАМАН ЮКСЫНАМ

Мине яратканнар очрап тора,
Үзем синең өчен өзеләм.
Бик-бик еракларда яшәсәң дә,
Җуя алмыйм сине күземнән.

Истә әле синең шаян сүзләр,
Истә һәрчак моңсу күзләрең.
Мин дә чая, шаян була беләм –
Сөйләп бетмәс кайчак сүзләрем.

Аралашсам, кызык сөйлим, диеп,
Әзерләсәм шаян сүзләрем.
Тик барысын бер мизгелдә җуям,
Искә төшәләр дә күзләрең.

Лилия ХӘЛИМ

«ЯЗМЫШЫҢА НИ ЯЗГАН…»

Моңа дистә еллар вакыт узып китсә дә, күргәннәрем һаман да күз алдында, ишеткәннәрем колак төбендә.

…Хатын-кызны гаиләсеннән, газиз баласыннан аерылырга, бер мизгелдә язмышына төзәтә алмаслык, кайтарып булмаслык үзгәрешләр кертергә ни мәҗбүр итә? Тормышны, ул нинди генә авыр сынаулар китереп куймасын, бер дә зарланмыйча үз җилкәсендә тартып барган әниләребез, апаларыбыз, сеңелләребез кай урында абына, нигә абына? Без әйтергә яраткан рәхимсез тормыш кына гаеплеме моңа?

Башымда азга гына да тынгылык бирми торган шушы сорауларга җавап эзләп, Татарстан Республикасының Кеше хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле Сәрия Сабурская белән ирләр һәм хатын-кызлар колониясенә юл алабыз. Анда ишеткән-күргәннәремнән шундый нәтиҗәгә киләм: сакчылар рөхсәтеннән башка адым да читкә каерыла алмаган тоткын хатыннар арасында төрлесе бар. Әмма берсе дә белмәгән-күрмәгән кешегә эч серләрен бушатырга ашкынып тормый. Аларга артыгын сөйләргә ярамый да. Чөнки биредәге тормышның үз законнары, үз тәртипләре. Сораштыра башласаң, кайсы идән юам, кайсы маллар карыйм, дигән сүзләр белән генә чикләнә. «Ияләштем инде…» – диләр. «Иң авыры, иң куркынычы ни булды?» – дигән сорауга һәркайсы: «Кулга алыну», – дип җавап кайтара. Җиде айлык авыры белән төрмәгә килеп эләккән ханым да шулай ди. «Хөкем карары укыганда аңымны җуйдым», – ди.

Йөз-кыяфәтенә, килеш-килбәтенә караганда, ул күпкә өлкәнрәк күренә. Ә үзенә нибары 25 кенә яшь икән әле. Сөйләве, сорауларыма теләр-теләмәс кенә җавап бирүе, ара-тирә «миңа беркайчан да уң килеп тормады» дип кабатлавы… искә төшкән саен сискәндереп куя. Әнисен алты елга төрмәгә утыртканда, ул әле бөтенләй бәләкәй була. Әбисендә үскән вакытларны: «Үземне гел ялгыз, тәрәксез хис иткәнемне, ярату-назга мохтаҗ булып яшәвемне хәтерлим», – дип искә алган иде ул. Бер уңмаган гел уңмый, диләр. Дөрестер. Вакыты җиткәч, ул кияүгә чыга. Кыз бала таба. Ике елдан аерылыша. «Холкыбыз туры килмәде», – ди ул. Аннан язылышмыйча гына башка ир белән яши башлый. Икенче балага уза. «Авырыма биш ай чамасы булгандырмы, туганнарга кунакка киттек, – ди хатын, күңеленнән бер дә китмәгән, тормышын бер кизәнүдә үзгәртергә мәҗбүр иткән ул мизгелләрне янә торгыза башлап. – Иремнең бик яман бер гадәте бар иде: көнләште ул, теләсә кемнән – урамнан узып баручыдан да, бер табын янында утыручыдан да… Бу юлы да: «Абый нигә сиңа карый, ник син аңа елмаясың?» – дип бәйләнде. Кызу кеше иде. Өйгә кайткач, кыйный башлады. Ә мин авыртуны тоймыйм, бары бер нәрсә турында уйлыйм: балага гына зыян китерә күрмәсен. Үзен-үзе белештермичә, пычак белән кизәнә башлады. Шунда мин түзмәдем, корсагыма чәнчи дип, кулыннан пычагын тартып алдым да, аны-моны абайламыйча, күкрәгенә китереп кададым. Җәрәхәт кенә ясаганмындыр дигән идем. Тотынды кан агарга. Җәрәхәтне сөлге белән бәйләргә азапланам, ирем ирек бирми. «Авырта…» – ди. Ул арада мин чакырткан ашыгыч ярдәм машинасы килеп җитте. Алып киттеләр. Мин дә аның белән бергә. Артымнан полиция хезмәткәрләре килеп җитте. Үземдә кайгы юк, һаман ирем турында уйлыйм. Үлмәсә ярый инде, дим. Нинди хәлдә калуымны ябып куйгач кына аңладым. Язмышыңа ни язган бит. Ирем үлде, ә мин менә төрмәдә…»

pixabay.com

Мондый хәлдә хатын-кыз ни эшләргә тиештер? Үз башыннан кичмәгән кеше моны әйтә алмый. Ләкин эшлисе эшләнгән. Ә законнар бар кешегә тигез. Башта хатынны Җинаятьләр кодексының 105 маддәсе буенча (алты елдан унбиш елгача) хөкем итмәкче булалар, анары гына, үз-үзен саклап калу өчен кылынган җинаять дип, өч ел да өч айга ирегеннән мәхрүм итәләр. Хатынны җиде айлык авыры белән төрмәгә озаталар. Тимер рәшәткәләр артында дөньяга килгән сабыен кочып үкси-үкси елый ул. «Кичер мине, мин гаепле», – дип, баласыннан гафу үтенә. Бәби тапкач, аны: «Полициягә килеп йөрерсең, сиңа күздән югалырга ярамый», – дип, төрмәдән чыгаралар. Күрәчәгедер инде, абыйсының туган көненә бара. Кемдер бу хакта инспекторга җиткерә. Һәм янә аны колониягә озаталар. Ә ике баласын – балалар йортына. «Сабыйларымны гаиләгә тәрбиягә алганнар. Хет ичмасам фотоларын гына булса да җибәрегез, дип язам. «Ярамый», – диләр. Иреккә чыгуга барыбер балаларымны үземә кайтарачакмын. Моның өчен бөтен көчемне куячакмын», – дигән иде ул шул чагында. Бергәдер алар. Чөнки ана теләгенә каршы киртәләр юк ул бу дөньяда. Балалар йортларыннан, тәрбиягә алынган гаиләләрдән баланы мондый әниләргә кире кайтару хәтта мөмкин булмаган эшкә әверелсә дә…

Мәдинә АВЗАЛОВА

ГЕНЕРАЛНЫ САГЫНУ

Патриотизм, ватанпәрвәрлек хисләре бик көчле иде без бәләкәй чакта. Сыйныфташым Нәфис белән «Яшь ленинчы» газетасындагы герой шагыйребез Муса Җәлилнең балачагын тасвирлап, кышын майкадан гына калып чаңгыда шуып барган фотосурәтен күреп, урам очындагы күлдәвек таучыгында без дә шуны кабатладык. Менә ичмасам без дә чыныккан кыю-тәвәккәл малайлар! Бер төштек таучыктан, ике – өшеттерә башлады, тик бер-беребезгә сиздермибез. Шуннан Нәфис:

– Муса Җәлил дә болай озак тормагандыр суыкта – без ул шуган чаклы гына шудык инде! – диде.

Шактый суык иде шул, иртән торуыбызга борыннарыбыз мышык-мышык килде, ләкин дәресне калдырмадык. Үткән атнада гына Павлик Морозов исемендәге пионер дружинасының яшь пионерлары булдык өстәвенә. Ә бераз үтүгә, Павлик атасын саткан дигән сылтау белән Зоя Космодемьянская исемендәге дружинага әйләндек.

Сыйныфташым Нәфиснең әтисе Кәлимулла абзый авылда гына түгел, районда, хәтта Татарстанда да иң батыр һәм ватанпәрвәр кешеләрнең берсе иде. Ул чынлап та тиңдәшсез каһарман: Бөек Ватан сугышының иң дәһшәтле Курск дугасында «Т-34» танкында фашистларның «Тигр»ларын чәлпәрәмә китергән, Берлинга барып җитеп, Рейхстаг диварына исемен уеп язган! Әле тагын ул – авыл советының алыштыргысыз председателе. Сыйныфташымның әнисе Зәйтүнә апа – ярты сәламәтлеген сугышта калдырган әтиемнең сыйныфташы да. Без ишле гаиләдәге алты малай үсеп буй җиткәнче үзебезнең күршебездә күп орденнар кавалеры Кәлимулла абыйга сокланып, үрнәк алып, аның кебек булырга тырыштык.

Ә безнең белән бергә язгы яланнар кардан ачылуга ук шәмәй сугып-уйнап үскән һәм алга таба авиация генерал-лейтенанты дәрәҗәсенә җитәсе Таһир Сәйфетдинов та янәшәбездә. Башлангыч сыйныфта мөгаллимә әнисе Зифа апа белән әтинең балачак чордашы Әгъҗәй абый белән Азнакайга күчсәләр дә, дустыбыз җәйге каникулларда бездән аерылмый иде. Берчак Таһир белән клубта танкчы Кәлимулла абыйга багышлап уздырылган кичәдә утырдык. Әйе, әйе, олы урам малайлары гына түгел, авылыбыз белән Кәлимулла абыйга тиңләшеп үстек.

Менә шуннан еллар агымында ни хикмәт: безнең Таһирыбыз, әллә бу ыру-нәселдәге туганы Кәлимулла абыйга карапмы, тәрбия-геннары тәэсиреннәнме, авылыбызда туган беренче генералыбызга әйләнде. Азнакай шәһәренең 2 нче урта мәктәбеннән соң хәрби академияне алтын медальгә тәмамлый һәм янәдән Жуков исемендәге академиядә укый. Генерал-лейтенант дәрәҗәсе ала, Брянск гарнизоны начальнигы булып, һава һөҗүменнән саклау корпусы белән командалык итә. Аның турында милләттәшебез армия генералы Мәхмүт ага Гәрәев: «Таһир Сәйфетдинов кебек сынаучы-очучы генераллар сирәк», – дип сөйли торган була. Әтисе Әгъҗәй абый исә: «Мин Кызыл Йолдыз орденын дәһшәтле яуда алсам, генерал улым аны тыныч тормышта алды», – дип горурлана иде. Менә шул хәрби стратегик кимәлдәге яңа очкыч-самолетларны туктаусыз үзе сынауларның тәэсиреннәнме, генерал авылдашыбызның гомере кыска була.

– Гел кайтып исәнләшеп, очрашып тора иде Таһирыбыз, үзенең дәрәҗәсен бер дә сиздерми иде, – ди бер сыйныфта укыган дусты Габдрахман Убайдуллаев. – Һәрчак ярдәмчел, ихлас замандашыбыз булып калды ул күңелебез түрендә.

Әйе, патриот-шагыйрь Муса Җәлил әйткәнчә: «Эш күрсәткән ирне ил онытмас!» Таһирыбызны Азнакаебыз зиратында җирләдек тә, шуннан бирле уфтанырга гына кала. Югары Стәрле авылының тәүге генералы турында анда яшәүчеләрдән: «Таһирны беләсезме?» – дип соравыма иңнәрен генә сикертеп куялар шул. Азнакай шәһәренең үзендә дә генералыбыз турында кем генә хәбәрдардыр? Аның кабере ни хәлдәдер хәзер? Моңарчы әтисе Әгъҗәй абый кайгыртып тора иде, ул да мәрхүм.

Әмма генералны онытырга хакыбыз юк. Бөек Җиңүнең 50 еллыгына әзерләнгәндә районда Советлар Союзы Геройлары өчәү дип исәпләнсә, дүртенчесе – Фәйзулла Әгъләтдинов моңарчы Башкортстан Герое дип йөртелә. Һәм мин, эзтабар буларак, аның районыбызның Сасы Күл авылы – хәзерге исеме Бүләктә дөньяга аваз салуын ачыклагач, шәһәребезнең Геройлар аллеясында каһарманның бюсты калыкты. Әлбәттә инде, туган авылында истәлек тактасы булдыру идеясе белән Сарлы биләмәсе башлыгы Марат Шәриповка чыгуыма, ул фикерне шундук күтәреп алды. Озак та үтми, зәвык белән ясалган мемориаль такта Бүләк авылы клубы урнашкан бина диварына беркетелде. Мәктәп музеенда да яңа материаллар өстәлде. Билгеле, бу – башка җирлекләрдәге данлыклы якташларыбызның исемнәрен мәңгеләштерү юлында өлге булырлык эш. Ә Югары Стәрле авылында туып-үскән генерал Таһир Сәйфетдиновның урыны җәннәттә булсын!

Әсгать СӘГЫТДИНОВ.
Азнакай районы Югары Стәрле авылы

Яшьлек хатирәләре

Җырлы авыл – җайлы авыл

Яшьлегемдә миңа Татар Шатрашаны авылында балаларга белем бирү насыйп булды. Бик матур табигатьле авыл ул, халкы да мәрхәмәтле, тырыш. Татар Шатрашаны туган авылым Зур Чынлыдан шактый ук ераклыкта. Велосипед та, мотоцикллар да юк вакыт. Ерак араны, бернигә санамыйча, тәпиләп кенә җырлый-җырлый барып җитә идем. Укытучылар коллективы бик тату, бердәм булды. Ачык дәресләр үткәрү, клубта концерт-спектакльләр кую да гадәткә керде, ата-аналар белән дә бик тыгыз элемтәдә идек, авылдан киткәч тә элемтәләр өзелмәде, «Шатрашан укулары» бәйрәмендә очрашып сөйләшеп, фикерләшеп, истәлекләр яңарттык.

Хезмәт эшчәнлеген башлаган авыл күңелгә бик якын, барысы да сагындыра. Сагынуым «Шатрашаным» дигән шигъри юлларга да күчте. Мин аңа көй дә яздым. Композитор Мәсгут абый Имашев нотага салды. Аңа олы рәхмәтемне җиткерәм.

Бер елны авыл бәйрәмендә шул җырны башкардым. Ошаттылар. Укучыларым: «Якташыбыз җырчы Илсафка җибәрик әле», – дип сорап та алды. Илсаф аны шулай ук ошаткан иде, чираттагы концертында җырлады да. Шунда ук Шатрашан кияве Иршат Алмакаев та җырга яхшы мөнәсәбәтен белдерде һәм үзенең туган авылы турында да җыр язуымны сорады. Мин рәхәтләнеп елмайдым гына, шулай да тора-бара күңелдә хис бөреләнде, аннан чәчәк тә атты, җыр туды.

Һәр авылның җыры булсын иде ул. Бу – авылга хөрмәт, авыл халкын олылау билгесе.

Барис САБИРҖАНОВ.
Чүпрәле районы

Сабырлыгы сокландырды

Әнкәемнең бакыйлыкка күчүенә инде 23 ел узса да, һәр хәрәкәте күз алдымда, әйткән сүзләре хәтердә. Әнкәй, колхозда эшләгәндә, төрле авырлыклар да кичерде, тән җәрәхәтләре дә алды. Трактор астында калып имгәнү, мотоциклдан егылып төшеп, бер кулының сеңерен өздерү, бозда таеп егылып, кулын сындыру дисеңме… Тома ятим үсүен дә ул яшерергә тырыша иде. Нинди генә авырлыклар күрсә дә, ул сабыр була белде. Чәпчемәде, берәүне дә гаепләмәде, күз яшьләрен дә күрсәтмәде. Бездә дә шул сыйфатларны тәрбияләргә тырышты, эшкә өйрәтте. Җәй көннәрендә колхозда өчәр гектар чөгендер утадык, утаган чүпне киптереп, кышка печән әзерли идек.

36 ел бергә гомер кичергән, дүрт баланы аякка бастырган, аларга яхшы тәрбия биргән җәмәгатем Нәкыя да бакыйлыкта инде. Ул да нәкъ әнием кебек сабыр холыклы, түзем, булганына шөкер итеп яшәүче иде. Икәү бергә хәзрәттән дини белем дә алдык, шуннан соң авылыбызда дини укулар да оештырдык. Әнием белән Нәкыямның балаларны тәрбияләүдә дә йогынтысы зур булды, балалар тырыш булып үстеләр, Алланың биргәненә шөкер. Яшьлек чоры уйландыра да, сокландыра.

Рафис МӨХӘММӘТОВ.
Азнакай районы Әсәй авылы

Әниебез истәлеге

Әниебез белән әтиебез Теләче районының Кече Нырсы авылында туып-үскәннәр, күршеләр булып гомер иткәннәр. 1953 елда өйләнешәләр, яшь кыз күршедәге егет йортына, борынгы матур гадәт буенча, шулай ук матур, күз явын алырдай бирнә сандыгы күтәреп керә. Сандыкка әниемнең чәчәкле яулыклары салынган була. Яшьлек елларында шул сандыкны ачып карыйбыз да әни күргәнче ябып та куябыз.

Без гаиләдә биш бала үстек. Әтиебез каты авырудан соң 41 яшендә бакыйлыкка күчә, әниебезнең вафат булуына да инде 20 ел. Исән-саулардан без – дүрт бала Казанда гомер итәбез. Авылга кайткан саен әниебезнең сандыгын ачып карамыйча, хатирәләрне барламыйча, яулыкларны җилләтмичә калганыбыз юк. Унлап яулык егерме ел инде кулланылмасалар да, бүген генә сатып алган кебек. Яулыкларда әнинең төсе, әнинең исе, алар әниебезнең мәңгелек истәлеге, беребез дә аларны ябып йөрергә батырчылык итми, ничек сакланган, шулай саклана күрсеннәр, яшь буынга да ничек бар шулай барып җитсеннәр, дигән фикердәбез.

Халисә НУРИЕВА

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Өлкәннәргә дә, яшьләргә дә мөрәҗәгать итүебез: нәкъ менә балачактагы хатирәләрне күңелегездә яңартып, «Һич онытасым юк» сәхифәсенә язмалар юллагыз әле. Үзегезгә үткәнгә кайтып килү булса, башкаларга соклану, йә булмаса гыйбрәт алу булыр.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Иң рәхәт чак – балачак!

Язучы сүзе

Марат КӘБИРОВ

Матурлык

Матурлык дөньяны коткарыр. Бу тәгъбир дөрестер ул. Колакка ятышлы булган өчен генә гасырлар буе халык телендә йөрмидер. Әмма матурлык ул абсолют төшенчә түгел.

Әле менә бәрәңге алып, җирен тазартып куйдык. И, матур булып тора инде. Кабат-кабат чыгып карыйм, караган саен күңел сөенә.

Казыган вакытта да шулай иде. Кара туфракта тәгәрәшеп яткан бәрәңгеләрдән дә матуррак нәрсә юктыр шикелле. Быелгы җәй уңыш өчен бик җай булмады бит инде, бернәрсә дә үсмәс инде дигән хәвеф тә юк түгел иде. Ә алар үскән! Аллы-сарылы нурлар сибеп тәгәрәшеп яталар. Сокланып, хозурланып туймаслык. Канәгатьлек хисе, рухи ләззәт җанга гына сыялмыйча, тәннең бөтен күзәнәкләрендә тирбәлә. Матурлык кына түгелдер бу, үзе бер могҗизадыр кебек тоела. Югыйсә дөнья шаулатырлык сәнгать әсәре дә, гайре табигый хәл дә түгел бит инде.

Көзнең бер матурлыгы бу. Көзнеке. Әгәр җәй уртасында кемдер бәрәңгеләрне казып, бакчаны тырмалап, тазартып куйса, бик сәер булып тоелыр иде. Хәтта шулкадәр үк бәрәңгесе чыкса да. Күз алдына китерегез менә: кешеләрнең бакчасында чәчәк тә, хәтта колорадо коңгызы да чыгып өлгермәгән, ә синекендә – уңыш. Күңел аны кабул итә алмас иде. Берәр зәхмәттер бу, юньлелек түгелдер дип уйлап, ул бәрәңгене беркатлы кешеләр чыгарып түгәр, ә малтабарлар базарга илтер, һәрхәлдә, андый сәер нәрсәне үзе ашарга кем дә куркыр иде.

Югыйсә җире дә, бәрәңгесе дә шул ук бит инде. Вакыты гына бүтән. Әгәр үз вакытында килмәсә, хәтта уңыш та матурлык булып күренми. Бәрәңге бакчасына гына кагылмый инде бу. Дан да, мал да, башкасы да шулай.

Без бу дөньядан киткән бөек затларыбызны данлыйбыз, исемнәрен урамнарга биреп, һәйкәлләр куеп хөрмәт күрсәтәбез, аларны телдән төшермәскә тырышабыз. Әйтик, бүген Тукай районы бар, урамнары бар… Ә үзе исән чагында шагыйрьнең үз йорты да булмаган. Заманының иң популяр, иң «кассовый» шагыйре бу. Әлбәттә, зурларга кирәк андый шәхесләребезне. Онытмаска, оныттырмаска кирәк. Ләкин кайчагында соңлап килгән дан-шөһрәтләр миңа чын хөрмәт кенә түгел, ә халыкның үз шәхесләреннән гафу соравы кебек тә күренә. Соңга калган бер генә нәрсә дә матурлык була алмый. Ул әрнү, үкенү, сагыш яки бүтән нәрсә булырга мөмкин, теләсә нәрсә булырга мөмкин, тик матурлык кына түгел.

Без барыбыз дә чәчәкләр яратабыз, аларга карап сокланабыз. Хәтта матурлыкның үзен дә чәчәкләр рәвешендә күз алдына китерәбез. Ләкин аларның барысын да яратмыйбыз. Үзебез күрергә теләгән урында үскәннәрен генә матурлык дип кабул итәбез. Менә ромашка турында әллә күпме җырлар бар. Болында үскәннәрен күреп сокланабыз, таҗларын өзеп, хыялга биреләбез. Ә менә шул чәчәк кыяр түтәлендә яки бәрәңге арасында үссә, чүп итеп күреп йолкып ыргытабыз. Һәрбер матурлык шулай: үзебез күрергә теләгән урында булса, ул – матурлык, күрергә теләмәгән җирдә калкып чыкса – чүп. Матурлык төрле урында төрлечә күренә.

Аның без кабул итә алырлык микъдарда булуы да кирәк әле. Артык якты булса, күзне чагылдыра ул, бик караңгы булса – томалый. Артык күп яки еш чагында, матурлык булудан туктап, гадәти күренешкә әверелә. Аз чагында гадәттән тыш хәл яки зәгыйфьлек сыман тоела. Һәрхәлдә, өлгереп җитмәгән нәрсә беркемдә дә соклану уятмый.

Без өметләнгән вакытта, без көткән урында, без теләгән рәвештә, без кабул итә алган микъдарда бирелгән һәм күңелебез халәтенә тәңгәл килгән һәрбер нәрсә матурлык була ала. Әйберләрнең, хәл-вакыйгаларның, күренешләрнең һ.б. матурлык булуы аларның үзләреннән түгел, ә кешеләрнең кабул итү мөмкинлегеннән тора. Без нәрсәне матур дип күрәбез, шул матурлык була.

Гомерегез матур узсын…

Лилия Гыймазова

ИКЕГЕЗ ДӘ БЕРТИГЕЗ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Казаннан 87 яшьлек Люция әби ялгызларны кавыштыра. Ул табыштырган ун гаилә матур гына гомер кичерә. Димче әби башкаларга шатлык өләшеп, үзенең дә ялгыз картлыгына ямь өсти.

– Ирем Саяф Кубада хәрби хезмәттә чакта нурланыш алган иде. Гомер буе ак кан авыруы белән чирләде. Шуңа күрә безгә, итәгебезгә утыртып, балалар сөяргә язмады. Ул утыз ел элек дөнья куйды. Шөкер, картлык көнемдә ялгыз түгелмен. Башкалардан игелек күреп яшим. Кавыштырган гаиләләрнең игелеген тоям, – ди Люция әби. – Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин – бик якын кешем, улымнан да якынрак. Көн саен хәлемне белешеп тора. Кан басымымны үлчәп, аңа әйтеп торам. Солтан, Нияз, Фәннур һәм башка хәзрәтләр белән дә элемтәне өзмим. Әҗәлем җиткән очракта да ярдәмнән ташламаячакларына ышанам.

Язмам героеның язмышы үзе бер китап язарлык. Әнисе Хөсникамал рәттән биш баласын югалта. Аннан өч баласын калдырып, үзе дә дөнья куя. Люциягә ул чакта нибары 2 яшь була. Ике ел элек апасы Данишә бакыйлыкка күчкән. Абыйсы Әдип 63 яшьтә үлгән. Әтисенең гомере сугыштан соң өзелгән. Аңа кадәр үги әни белән дә яшәргә туры килә кызчыкка. Кыерсытуга түзмәгәч, әби-бабасы янында үсә. Соңрак Люцияне вакытлыча балалар йортына тапшыралар. «Аллага шөкер, юлдан язмадык», – ди ул. Мәктәпне тәмамлагач, Башкортстанның Иске Шаһ мәктәбендә бер ел укытучы булып эшли. Укыткан чакта аны Уфага хокук органнарына эшкә чакыралар. Шул вакытта юридик мәктәпкә укырга керә. Тик тәмамларга насыйп булмый.

Очучы Әдип абыйсы сеңлесенә башкалага КХТИның механика факультетына укырга барырга тәкъдим итә. Шуннан соң аны юллама буенча «Оргсинтез» оешмасына җибәрәләр. Гомер буе шунда бер урында утыз елдан артык хезмәт куя.

– Иҗтимагый эшләрдә еш катнаштым. Бала-чага булмагач, эш күп кушалар иде. Ирем Саяф бик ышанычлы булды. Соңга калсам да, көнләшеп, тавыш куптармады, – ди Люция әби.

Дингә ышану әби-бабасыннан килә. Калганы – Рамил Юныс дәвамы. Дини нәзарәтендә хәйриячелек буенча ун ел эшләгән Люция апа. Рамил хәзрәт белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә вәгазь тыңларга йөргән чакта танышкан.

– Берсендә шулай игътибарсыз гына утыруымны күреп, үз янына чакырды. «Нигә син мине тыңламыйсың?» – ди. Уфадан абыемны күмеп килдем, бернинди хәлем дә юк, дип аңлаттым. Урын бар, иртәгә үк эшкә чык, диде. Ул вакытта мин инде пенсиядә. Иптәшем үлгәнгә дә шактый вакыт узган иде. Саяфем 55 яшьтә мәңгелеккә китеп барды. Аның белән 30 ел бик тату яшәдек, – дип сөйли ул. – Иптәшем үләр алдыннан: «Мәчеткә йөр, намаз укырга өйрән. Мин синең догаңны көтәрмен», – диде. Минем өчен әйтелгән сүз – атылган ук. Намазга бик җиңел бастым.

Мәчеттә эшләгәндә ялгыз парларны да кавыштыралар.

– Кавыштыру авыр түгел. Моның өчен дөрес итеп аңлата һәм бер-берсенә охшаганрак холыклы ярларны сайлый белү кирәк. Башта холык-фигыльләрен яхшылап өйрәнәм. Шуннан башка таныштырып булмый. Минем өчен аларның дин тотуы, намаз укуы мөһим. Аллаһка ышанган кешеләр бер-берсен аңлый, матур гаилә кора. Иң элек ышану, көнләшмәү кирәк. Көнләшү ул – шайтан эше. Егет белән кыз яратуны саклый белгәндә, никах бәхетле, озын гомерле була. Аерылышуга юл куймагыз! Һәркем хатаны үзеннән эзли, бер-берсеннән гафу үтенә белсә, тормыш дәвам итә, – дип киңәшләрен бирде Люция әби.

Сәрия МИФТАХОВА

Шөгыль

ГӨМБӘЧЕ НӘФИРӘ ИГЪЛАМОВА: «СЕЗОНЫНА 180 МЕҢ СУМ АКЧА ЭШЛИБЕЗ»

Казанда яшәүче Игъламовлар гаиләсе инде 11 ел гөмбә җыеп, аны тозлап, маринадлап кәсеп итә. Гөмбә җыю теләге Нәфирәгә декрет ялында утырганда килә.

– Ялымны да көзгә калдырам хәзер. Рәхәтләнеп тыныч кына гөмбә җыям. Республиканың төрле районнарына барабыз. Мамадыш, Питрәч, Лаеш, Спас районнарында гөмбә күп. Узган ел, гөмбә сатып, 180 мең сум акча эшләдем. Ипотека түләгәндә бик зур ярдәм инде бу, – ди Нәфирә.

Гөмбәне кечкенәдән аера белә икән. Укытучысы Мәдинә апа оста урманчы булган. Барысына да ул өйрәткән. Әлегә алар майлы гөмбә җыялар. Озакламый нарат гөмбәсе өлгерәчәк.

– Гөмбәне эшкәртергә дә өйрәндем. Үземнең генә белгән серләрем бар. Төсләрен матур итеп сакларга тырышам. Кешеләр әзерләгән гөмбәмне бик ярата. Кайчак ясап кына куям, килеп алып та китәләр. Ничә еллар буе шушы эш белән шөгыльләнгәч, үз клиентларыбыз да күп. Өлгереп тә булмый кайчак. Кемгәдер җитми дә кала, – ди оста гөмбәче.

Әле менә өч көн эчендә 40 мең сумлык гөмбә әзерләп куйганнар. Быел акчасын да күбрәк эшләргә өметләнеп торалар. Гөмбәсе бар, алучылары җитәрлек, калганын исә Нәфирә булдыра.

– Гөмбәне җыю да, эшкәртү дә бик рәхәт эш. Минем өчен ял ул. Гөмбәләрне юганда бар дөньямны онытып, уйларга чумам. Эшне бит аны

яратсаң гына эшләп була. Иң мөһиме – иренмәскә кирәк. Туган авылым – Яшел Үзән районының Мамадыш-Әкил авылында да тырыш халык яши. Алар бар яктан булган. Эшләп яшәү безгә кечкенәдән сеңдерелгән. Эшлисең икән, ризыгың бар дигән сүз, – ди Нәфирә.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Нәфирә ИГЪЛАМОВАдан гөмбә тозлау рецепты

– Гөмбәне юып, кайнап торган суга салам. Кайный башлап, 2–3 минут тоткач, уттан алып, дуршлагка бушатам. Аннары гөмбәне яңадан юам да тагын 15–20 минут пешереп алам. Анысын дуршлаг аша сөзәм. Кәстрүлне юып, тозлык ясыйм. Суны гөмбә күләменә карап салам. Тоз, әзрәк шикәр комы, кара исле борыч, канәфер, дәфнә яфрагы өстәп, гөмбәне шуңа салып 3–5 минут кайнатам да кайнар килеш банкаларга тутырып, каплап куям.



Бәбәй кирәк!

Уйлы күңел уйлана

Август ахырлары иде. Авыл кибетенә барсам, ун-унике яшьләрдәге таныш түгел яшүсмер малай кибеткә кергән һәр өлкән кешегә сүз ката. Татарчасы әллә ни чиста түгел, әмма бик тырышып татарча, әдәп белән, бик ипле сөйләшә. Сатып алган әйберләр турында да сөйли, кешеләрнең сүзләренә дә катнаша.

Күренеп тора: сөйләшәсе, аралашасы килә. Миннән алда берничә әйбер генә алды да, ияреп, кибеттән чыкты. «Кая, сумкагызны бирегез», – дип, әле ярдәм итәргә дә теләде. «Авыр түгел», – мин әйтәм. Мин сорау биргәнче сөйли дә башлады. «Казаннан кайткан идем. Авылда дуслар табармын дип уйлаган идем. Урамда малайлар күренми дә», – ди бу. «Эссе бит, – дим. – Алар өйләрендә, телефонда инде…»

«Шәһәрдә дусларым күп иде, әти-әни, татарчаны да әйбәтләп өйрәнерсең, анда тыныч та дип, авылга кайтарды. Бер ай өйдә яттым менә. Урамга чыгып керәм, тик балалар юк. Ә Казанда без сыйныфташлар белән бик дус, алар анда каникулда да күңелле итеп аралашалар. Телефоннан гына инде». «Телефоннан да кара-каршы, бер-берегезне күреп сөйләшкәч әйбәт бит инде», – диюемә ул: «Юк шул, телефон дусларны алыштырмый. Аның белән сөйләшеп була, әмма очрашып булмый», – диде, җитдиләнеп.

Чын ихластан кызганып куйдым үзен. Мөгаен, әти-әнисе авылда балалар элекке кебек, үзләре үскәндәге кебек, урам тутырып уйный дип уйлагандыр инде. Авылда хәзер көндез яки кичен урамда балалар очрату гайре табигый хәл шул, кызганычка. Бигрәк тә безнеке кебек артык зур булмаган авылда. Хәер, кайчакта авылның бар бала-чагасы тау башындагы заманча уен мәйданчыгына җыйнала: кычкырышалар, чыр-чу киләләр. Андый чакта авылга ямь керә. Бу балакай, мөгаен, аларның мәйданчыкка килгән чагын туры, китерә алмагандыр. Уйлап куйдым әле: без, хәзерге балаларга телефон булса, башка берни кирәкми, диргә яратабыз. Алай гына түгел икән бит. Ялгызлыкны, бушлыкны телефон гына тутыра алмый – менә бу үсмер кебек, аны аңлаучылар бар икән бит инде. Мөгаен, балалар аны никадәр иртә аңласа, шулкадәр әйбәттер дә.

Тагын бер шундый кечкенә танышым бар. Төгәлрәге, танышларымның биш яшьлек кызлары Әдилә. Ул моңа кадәр үзенең бердәнбер булуына әллә ни борчылмады. Бакча – телефон, телефон – бакча дигән «бөҗра»да көннәре үтә торды. Әти-әнисенең: «Кызым, бәби алып кайтабызмы?» – дигән сүзләренә дә: «Юк!» – дип кистереп кенә җавап бирә, әнисе берәр чит кешенең баласын кулына алса, йөгереп килеп җитә, кире бирдерткәнче тырыша иде. Берәрсе, шаярып кына: «Мә, бу бәбине сезгә бүләк итәбез, алып кайтып кит», – дип кечкенә бала суза башласа да, ихластан ышанып: «Бирмәгез, кирәкми!» – дип елый башлый иде. Бер-ике яшь аерма белән абый-апа булган яшьтәшләреннән аермалы буларак, ул сабыйлыкның бөтен тәмен, рәхәтен аңлый, аны башка кем белән дә булса бүлешергә әзер дә түгел иде. Телефон аңа барысын да алыштыра иде кебек. Бер караганда, үтә акыллы иде бу сабый. Нигә, әби-бабай, әти-әни, туганнар назы-яратуы, кадер-игътибары барысы да үзенә. Уенчык, тәти киемнәр, атынчык, сәпид-самокат дисеңме, һәрьяктан үсәр өчен җайланма-әсбаплар дисеңме… – алары да үзенә. Телефоны да шәп, яңа! Авылда яшәсәләр дә, зоопарк, циркка – шәһәргә «тузан кундырмадылар». Барам дисә, кая тели – шунда алып бардылар, ул – һәркайда көтелгән кунак! Тик быел ул якыннарын гаҗәпкә калдырып, бу кадәр игътибардан, төгәлрәге, өлкәннәр камалышындагы, телефонлы ялгызлыктан туйды, бөтенесе үзенә генә булудан тәмам арыды.

Һич уйламаганда, истә-оста югында: «Бәбәй кирәк! Апай буласым килә!» – дип шаккатырды ул өлкәннәрне. Шул көннән башлап, телендә фәкать шул бер сүз: «Бәбәй кирәк!» Телефоннан баш күтәрмәгән сабыйның анда бөтенләй гаме дә калмады дип аптырый өйдәгеләре.

Әйе шул, телефон дусларны да, туганнарны да алыштыра алмый. Без исә һаман да: «Ярый әле телефон бар!» – дибез…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы
Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ,
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ
Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.
Тираж – 5159 данә
Гомуми тираж – 14047 данә
Газетага сертификат бирелде Заказ 326

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.
Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.
Ваклап сату бәясе килешү буенча.
Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**
16+